yz. K. w 24
A. T. S. S. Ç. Qazan LENIN isem.
ƏLKƏ MASSA KITAPXANƏSE TƏP KITAP SAQLAV BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань

СИШӘМБЕ
12 МАРТ
1940 ел
№ 59 (5859)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: *Казан, Матбугат йорты.* ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ЭШЕ ТУРЫНДАГЫ ОТЧЕТТАН

*ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **А. М. Алемасов** доклады*

Иптәшләр! Отчет чоры эчендә ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының бөтен эше нигезендә партиябезнең XVII нче һәм XVIII нче съезды карарлары, ВКП(б) ның ленинче-сталинчы Үзәк Комитеты карарлары, бөек Сталин күрсәтмәләре, партиянең XIX нчы һәм XX нче Өлкә конференцияләре карарлары торды.

Отчет чоры Татарстан партия оешмасының үзенең сафларын оешу һәм идея ягыннан тагын да ныгыту өчен, масса белән үзенең элемтәсен тагын да киңәйтү өчен көрәш чоры булды, Татарстан республикасының халык хуҗалыгын һәм культурасын тагын да **үстерүгә һәм күтәрүгә хезмәт ияләрен туплау** өчен көрәш чоры булды.

I. ПРОМЫШЛЕННОСТЬ

Татарстан АССР промышленностена анализ ясау аның бер туктаусыз үсүен күрсәтә. 1937 нче елны Татарстан АССР ның бөтен промышленностеның тулай продукциясе (1926—27 нче елгы бәяләр белән) 834,1 миллион сумлык булган булса, 1939 нчы елны ул 1.132,4 миллион сумлык булды. Үсеш—35,7 процент. Шуның белән бергә, үсеш темплары буенча иң алда эре промышленность бара. 1937 нче елны ул 740,3 миллион сумлык, ә 1939 нчы елны 1.022,6 миллион сумлык тулай продукция бирде. Үсеш—55,8 процент.

1937 нче елны бөтен халык хуҗалыгында промышленностьның тоткан урны 74,8 процент булган булса, 1939 нчы елны инде ул 86,0 процентка җитте. Шуның белән бергә, эре промышленностьның тоткан урны 1937 нче елгы 66,4 проценттан 1939 нчы елны 77,6 процентка кадәр күтәрелде. Эшчеләр саны да туктаусыз үсә: 1937 нче елны алар 105.026 кеше булган булса, 1939 нчы елны 115.574 кә җиттеләр. Үсеш—10,0 процент. 1937 нче елны бер эшченең уртача эшләп чыгарышы 7.944,8 сумлык булган булса, 1939 нчы елны ул 9.798 сумлык булды. Үсеш—21,7 процент. Шуның белән бергә, эре промышленностьта эшләүче һәрбер эшченең уртача эшләп чыгарышы 26,5 процентка артты.

Ләкин ТАССР промышленносте эшенең туктаусз яхшыруын күрсәтә торган бу гомуми саннар артында әле промышленностьның аерым тармакларының һәм кайбер предприятиеләрнең бөтенләй канәгатьләнмәслек хәлдә торулары яшренеп ята. Бу нәрсә тулай продукция эшләп чыгаруда аеруча ачык күренә.

Бөтен Союз күләмендә әһәмияте булган промышленностьта тулай продукция үсеше 44,5 процент булса, республика күләмендә әһәмияте булган промышленностьта ул бары 17,2 процент кына булды. Район промышленностеның торышы тагын да начаррак. Анда үсеш 10,7 процент кына. 1939 нчы елгы планны үтәүгә килсәк, Союз промышленносте да, республика промышленносте да, район промышленносте да план үтәлешен башкарып чыга алмадылар. Боларда үтәлеш 92,6 процент, 99,3 процент һәм 90,5 процент. Бу әле 1939 нчы елгы планны үтәгән предприятиеләр юк дигән сүз түгел. Уннарча предприятиеләр уңышлы эшләделәр. Шундыйлардан Мехкомбинатны, Вахитов исемендәге Жиркомбинатны, „Спартак"ны, язу машиналары заводын, ит комбинатын, „Светоч" фабрикасын һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин. Шул ук вакытта Союз күләмендә әһәмияте булган кайбер предприятиеләр бөтенләй канәгатьләнмәслек эшләделәр. Мәсәлән, 4 нче ясалма каучук заводы планны үтәмәде, җитен комбинаты 54,8 процентка, Кинопленка—67,5, ясалма күн заводы—57,2, Энергокомбинат—88,6, 3 нче фанер заводы—92,4, 10 нчы фанер заводы—88,8 һәм коры сөт заводы 97,6 процентка гына үтәделәр.

Татарстан АССР наркоматлары буенча күрнеш тагын да күңелсезрәк. Мәсәлән, ТАССР Совнаркомы янындагы Төзү Материаллары Идарәсе 1939 нчы елгы планны бары 68,9 процентка гына, Наркомлес 75 процентка, Наркоммолмясопром—91,1, Наркомлегпром—97,8 процентка гына үтәделәр. Бары тик Наркомместпром гына программаны 100,2 процент итеп һәм Наркомпищепром—104,9 процент итеп үтәделәр. Ләкин Наркомместпромның да үзенең планын бары тик язу машиналары заводы исәбенә генә үтәгәнлеген әйтергә кирәк. Наркомпищепром системасында да шул ук хәл: анда ун предприятиедән бары биш предприятие генә планнарын үтәделәр.

Наркомлегпромның 8 предприятиесе планны үтәмәде һәм илебезгә 533 мең пар киез итек, 146 тонна каты күн товарлары, 13 мең пар яловый аяк киемнәре бирел җиткермәде һ. б.

Югарыда күрсәтелгән наркоматларның канәгатьләнмәслек эшләүләре аларның продукциясенең сыйфаты өчен йомшак көрәшүләрендә дә чагылды. „Спартак" комбинаты 1939 нчы елны продукцияләрнең сортлары буенча 271 мең сум, Казандагы киез итек фабрикасы—1.200 мең сум, Кукмарадагы киез итек фабрикасы—651 мең сум югалту ясады. 1 нче, 2 нче һәм 6 нчы тегү фабрикаларында брак 25 процентка җитә.

Наркоматларның һәм предприятиеләрнең җитәкчеләре финансларга игтибарсыз карыйлар. Бу хәл хезмәт хакы фондларын гаять зур күләмдә артык тоту белән расланa. Татарстан республикасында наркоматлар буенча гына да 1939 нчы елны хезмәт хакы фондларын артык тоту 5.977 мең сумга җитә.

Татарстан промкооперациясе әһәмиятле товарлар буенча 1939 нчы елгы планны үтәп җиткермәде һәм халык хуҗалыгына 4,5 миллион данә кирпеч, 67,9 мең пар аяк киеме, 287,2 мең пар оек һәм оек баш, 14 мең чемодан һәм башкалар бирел җиткермәде.

Казан тимер юлының эше канәгатьләнмәслек булды һәм әле дә шулай. 1939 нчы елны йөк йөртү планы 95,3 процент кына үтәлде. Шул ук вакытта юлның паркында вагоннар нормага караганда артыграк булды. Юл регулярләштерү заданиеләрен әледән-әле үтәмәде, ягни күрше юлларга вагоннар бирмәде һәм шулай итеп аларның эш күрсәткечләрен өзде.

Тимер юл транспортының бәләсе булган һәлакәтләр һәм аварияләр Казан тимер юлында шушы вакытка кадәр еш күренә. 1939 нчы елны күп кенә һәлакәт һәм аварие булган. Монда күп санлы браклар турында сөйләп торасы да юк. Алар аерым вагоннарның гына түгел, бәлки паровозларның да өзелеп китүләрен китереп чыгардылар. Кыскасы, Казан тимер юлы 1939 нчы елны барлык күрсәткечләр буенча 1937 нче елдагыга караганда начаррак эшләде.

Су юлы транспортында да эш яхшыдан түгел. Пароходларны навигациягә хәзерләү начар бара.

Иптәш Алемасов Казан пристанендә йөкләрне төяү-бушатуда шушы вакытка кадәр артта калган, кустарьчылык методлары хөкем сөрү турында, судноларга ремонтның вактында ясалмавы һәм түбән сыйфатлы итеп ясалуы турында сөйли.

1939 нчы елны промышленностька һәм транспорт төзелешенә 238,5 миллион сум акча салынды. Шушы ук чор эчендә ТЭЦ № 2, „Искож", 3 нче номерлы икмәк заводы кебек предприятиеләр эксплоатациягә тапшырылды, фото-желатин заводын һәм Кинопленка фабрикасының колокселин производствосын төзү тәмам булды һәм ходка җибәрергә хәзерләнелә, 4 нче ясалма каучук, Ленин исемендәге һәм Серго Орджоникидзе исемендәге заводларда яңа корпуслар эксплоатациягә тапшырылды.

Иптәш Алемасов, капиталь төзелеш эшенә зур игтибар бирелүгә, дәүләт тарафыннан зур күләмдә акча җибәрелүгә карамастан, Татарстандагы бер генә төзү оешмасының да планны үтәмәвен күрсәтеп үтә. 14 нче номерлы трест, Казпромстрой, Кинохимстрой трестлары, 4 нче ясалма каучук заводы, Казан тимер юлы, „Искож" заводы, җитен комбинаты төзелеш заданиеләрен үтәмәделәр.

Отчет чоры промышленность һәм транспорт эшчеләре арасында социалистик ярышның һәм стахановчылык хәрәкәтенең тагын да үсүе белән характерлы. Промышленностьта (район промышленностен исәпкә алмаганда) стахановчылар саны 1938 нче елның 1 нче январена булган 20.986 кешедән 1940 нчы елның 1 нче январена 31.586 кешегә җитте һәм эшчеләрнең гомуми составының 33,5 процентын алып тора. Шушы ук чор

эчендә **фабрикаларыбыздагы, заводларыбыздагы һәм транспортыбыздагы иң яхшы стахановчылардан 56 кеше ССР** Союзы хөкүмәте тарафыннан орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. Татарстан республикасындагы предприятиеләрнең зур күпчелеге Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышка кушылды.

Күп станокка хезмәт күрсәтүгә күчү турында Москваның „Красный Пролетарий" заводы коллективының чакыруын Татарстандагы күп кенә предприятиеләр зур күтәренкелек белән каршы алдылар. С. М. Киров исемендәге 4 нче ясалма каучук заводы аппаратчыларыннан Ураинская, Большакова, Соколова һәм Маркухина иптәшләр „Красный Пролетарий"чыларның чакыруын беренче булып күтәреп алдылар һәм илебезнең бөтен ясалма каучук промышленностенда күп станокта эшләүчеләр хәрәкәтенең инициаторлары булдылар. Хәзер 4 нче ясалма каучук заводында күп станокта эшләүче 156 эшче бар. Алар продукция эшләп чыгаруны нормадан тыш 15—16 процент күтәрүгә ирештеләр. Ленин исемендәге заводта күп станокта эшләүче 94 эшче бар. Орденлы Миңгалиев, Новоселова һәм Гобәйдуллина иптәшләр 2—3 станокта һәм агрегатта эшлиләр һәм аларның һәр кайсы билгеләнгән норманы 110 проценттан 150 процентка кадәр үти. Серго исемендәге заводта 121 кеше 184 станокта эшләү урнына 387 станокта эшли. Безнең предприятиеләрдәге стахановчылар хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча 5 еллык планны 4 елда үтәү турында Москва инструментальщикларының чакыруын да алкышлап каршы алдылар.

Стахановчылык хәрәкәтен большевикларча оештыручы фабрикалар һәм заводлар белән бер рәттән, стахановчылык хәрәкәте һәм күп станокта эшләүчеләр белән шөгыльләнмәүче предприятиеләр дә аз түгел. Болар исәбенә М. Горький исемендәге завод, Серго Орджоникидзе исемендәге завод, „Урак һәм Чүкеч" заводы, җитен комбинаты, Энергокомбинат һәм ТЭЦ №2 керәләр. Татарстанның урман промышленносте наркоматы системасында стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек эше аеруча канәгатьләнмәслек тора. Монда эшчеләрнең бары 9,5 проценты гына стахановчылар.

Промышленностебызның һәм транспортыбызның эшендәге югарыда күрсәтелгән кимчелекләрнең сәбәпләре нәрсәдә соң?

Төп сәбәпләр алты:

Беренчедән—Татарстан республикасындагы наркоматларның күп кенә җитәкчеләре һәм промышленность предприятиеләре җитәкчеләре, партиянең XVIII нче съезды директиваларын төгәл үтәүне оештыру өчен партия һәм ил алдында җаваплылык хисләрен югалтканнар. Бу кешеләрдә дәүләт дисциплинасы бик түбән, килеп чыга торган кыенлыкларны җиңү өчен большевикларча көрәш юк, үз-үзеңне страховать итәргә омтылыш зур. Бу нәрсә бигрәк тә урман промышленносте наркомы иптәш Газизевкә, җирле промышленность наркомы иптәш Филимоновка, төзү материаллары идарәсе начальнигы иптәш Королевка, Казан тимер юлы җитәкчеләреннән Пичугин һәм Мандур иптәшләргә, ТЭЦ № 2 директоры иптәш Коваленкога һәм кайбер башка иптәшләргә кагыла.

Икенчедән—начар эшләүче предприятиеләрнең директорларына һәм наркомнарга карата ТАССР Совнаркомы тарафыннан кирәкле таләпнең булмавы. Таләпнең булмавы гына түгел, бәлки начар эшләүче наркомнарны партия оешмаларының тәнкыйтләвеннән яклау. ТАССР Халык Комиссарлары Советы җирле промышленность наркоматларында һәм предприятиеләрендә партия һәм хөкүмәт директиваларының үтәлешенә контроль оештырмады.

Өченчедән—күпкенә предприятиеләрнең җитәкчеләре стахановчылык хәрәкәтенең һәм аның иң югары формасы булган күп станокчылар хәрәкәтенең политик һәм хуҗалык ягыннан гаять зур әһәмиятен шушы вакытка кадәр аңламаганнар. Бу хәл Татарстандагы фабрикаларда һәм заводларда күп станокларда эшләүчеләр санының бик аз булуында, күп кенә предприятиеләрдә стахановчыларның дистәләп кенә саналуында күренә. Төзү оешмалары эшчеләре арасында стахановчылык хәрәкәтенең үсүе аеруча начар. Болар барсы да стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итүнең еш кына икенче дәрәҗәдәге работникларга тапшырылуыннан килеп чыга. Нормаларны үтәмәүче һәм шулай итеп стахановчылар хезмәтенең нәтиҗәсен юкка чыгаручы эшчеләргә җитәкчеләр аз игтибар бирәләр.

Дүртенчедән—күп кенә профсоюз оешмалары ВЦСПС ның VIII нче пленумы карарларын үтәмиләр, производство киңәшмәләренең әледән-әле чакырылуына һәм аларның карарларының тормышка нык үткәрелүенә ирешмиләр. Профсоюз работниклары производствода җиһазларның эшсез торуларын бетерү өчен һәм югалтуларга каршы көрәшмиләр. 1939 нчы елны җитен комбинатында гына да эшсез торулар барлык эш вактының 34,8 процентына җитте. Профсоюз работниклары хезмәтне саклауга һәм куркынычсызлык техникасына җибәрелә торган сумалардан системалы рәвештә файдаланып җиткермәү белән килешеп торалар. Профсоюз оешмалары масса һәм культура эшен оештыруга билгеләнгән сумалардан да файдаланмыйлар. Мәсәлән, ит-сөте промышленносте, мехчылар профсоюзлары дингә каршы пропагандa эшенә җибәрелгән суманың бары 13,5 процентын гына тотканнар.

Бишенчедән — республикабызның промышленность предприятиеләрендәге күп кенә башлангыч партоешмалар партия уставының 61 нче параграфын үтәмиләр, администрация эшенә контроль булдырмыйлар, производствода массовый-политик эшне тиешенчә оештырмыйлар, планнарны үтәүгә массаны тупламыйлар. Җитен комбинатының партия оешмасын мисаль итеп алырга мөмкин. Бу оешма производство мәсьәләләреннән читтә тора. Нәтиҗәдә цехларда эшләүче 108 коммунисттан бары 8 кеше генә стахановчылар. Мех комбинатында эш башкача. Анда партия оешмасының оештыручылык роле нәтиҗәсендә, станокта эшләүче 267 коммунист арасында 183 кеше стахановчы һәм 59 кеше ударник. Район промышленностена килгәндә исә, турыдан-туры әйтергә кирәк: авыл районнарындагы партия райкомнары бу тармакка җитәкчелек итмиләр диярлек.

Алтынчыдан — партия Өлкә Комитеты, промышленностьның эшенә игтибарын көчәйткән булса да, аңа җитәкчелекне яхшырткан булса да, күп кенә наркоматлар һәм предприятиеләр җитәкчеләренең эшендә кирәкле борылышны тәэмин итә алмады, производстводагы барлык башлангыч партоешмаларның фабрикалар һәм заводлар администрациясе эшенә, бигрәк тә артта калучы предприятиеләрнең администрациясе эшенә контрольне яхшыртуларына ирешә алмады.

Промышленность өлкәсендә якын вакыт эчендә партиянең Татарстан оешмасы алдында нинди бурычлар тора соң?

Төп капиталистик илләрне экономик яктан да куып җитү һәм узып китү турында ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын һәм бөек Сталинның күрсәтмәләрен үтәүгә хезмәт ияләрен туплап, без Татарстан АССР промышленность продукциясенең 1940 нчы елны 1939 нчы ел планына карата кимендә 14 процент күләмендә гомуми үсешенә ирешергә тиешбез. Капиталь төзелеш буенча Татарстан республикасы 1940 нчы елда кимендә 300 миллион сум үзләштерергә тиеш. Партиянең Татарстан оешмасының бурычы—тимер юл һәм су юлы транспортының эшен яхшы итеп оештыру.

Татарстан большевиклары 1940 нчы елны промышленность өчен нефть чыгаруга күчү һәм җирле ягулык (күмер һәм торф) чыгаруны киңәйтү мәсьәләләрен хәл итәргә тиешләр.

Бу әһәмиятле һәм мактаулы бурычларны уңышлы төстә тормышка ашыру өчен партия оешмаларының эшен тамрыннан яхшыртырга, предприятиеләребезнең һәм наркоматларыбызның хуҗалык җитәкчеләренең җаваплылык хисен күтәрергә, стахановчылык хәрәкәтен һәм аның иң югары формасы булган күп станокчылар хәрәкәтен киңрәк җәелдерергә, аны барлык чаралар белән якларга, төрле юллар белән популярләштерергә, рационализаторларның һәм уйлап табучыларның иҗад инициативасын оештырырга, финанс дисциплинасын ныгытырга кирәк. Администрациянең эшенә көндәлек контрольлек булдыру турында партия уставының 61 нче параграфы таләбен изге төстә үтәргә һәм администрация эшендәге кимчелекләрне төзәтергә, кимчелекләрне кискен рәвештә тәнкыйть итәргә, эшлексезләрне һәм болтуннарны җитәкче постлардан рәхимсез рәвештә куарга һәм үзләрен эштә аклаган һәм Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән кешеләрне кыю рәвештә күтәрергә кирәк.

II. АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Отчет чоры эчендә Татарстан республикасында авыл хуҗалыгының үсеше түбәндәге юллар белән барды:

Беренчедән, чәчүле парга уҗым чәчүлекләрен кыскарту, техник һәм терлек азыгы культуралары чәчүлекләре мәйданын арттыру исәбенә чәчү мәйданнарын беркетү һәм аларның структурасын үзгәртү юлы белән. Бу чор эчендә техник культуралар чәчү мәйданы 88,7 мең гектардан 102,35 мең гектарга кадәр, ә терлек азыгы культуралары чәчү мәйданы 167,6 мең гектардан 245,1 мең гектарга кадәр үсте.

Икенчедән, авыл хуҗалыгын коллективлаштыруны тагын да үстерү юлы белән. 1937 нче елны Татарстанда барлык крестьян хуҗалыкларының 91,4 процентын берләштергән 3.836 колхоз булган булса, 1939 нчы елны колхозлар 3.893 кә җитте. Аларда 425,6 мең йорт берләшкән. Бу—барлык крестьян хуҗалыкларының 94,6 проценты дигән сүз.

Өченчедән, республиканың авыл хуҗалыгында колхозларның чәчү мәйданнарының тоткан урны арту һәм ялгыз хуҗалыкчыларның чәчү мәйданнарының тоткан урны кимү юлы белән. 1937 нче елны ялгыз хуҗалыкчыларның чәчү мәйданы 16,9 мең гектар булган булса, 1939 нчы елны бары 7,2 мең гектар гына, ягни 0,2 процент кына булды. Бу, 1939 нчы елны Татарстан республикасында колхозларның чәчү мәйданы колхозчы крестьяннәр секторындагы барлык мәйданнарның 99,7 проценты дигән сүз.

Дүртенчедән, республикабыздагы колхозларның һәм совхозларның техника ягыннан коралланулары тагын да үсү юлы белән. 1938 нче елның 1 нче январена республикада 5.171 трактор булган булса, 1940 нчы елның 1 нче январена инде алар 6.334 кә җиттеләр. Үсеш—22,5 процент. Тракторлар паркының куәте 38,3 процентка, яки 34.416 ат көченә үсте. МТС ларның комбайннар паркы 1937 нче елгы 1.717 машинадан 1939 нчы елны 2.788 гә җитте, яки 62,3 процентка артты. Республикабызның МТС ларында йөк автомобильләре саны 31,7 процент үсте. 1937 нче елны 91 МТС бар иде, 1939 нчы елны алар 103 кә җиттеләр.

Татарстан АССР игенчелеген хәзерге заман техникасы нигезендә социалистик үзгәртеп кору нигездә тәгәлләнде. Иптәш Сталин сүзләре белән әйтергә безнең тулы хокукыбыз бар: „...Колхозлар тәмам беркетелделәр һәм ныгыдылар, ә хуҗалыкның социалистик системасы хәзер безнең игенчелегебезнең бердән-бер формасы булып тора" (иптәш Сталинның ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладыннан).

Республикабыздагы колхозларның техник яктан нык коралланган булуларына да карамастан, авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә партиянең һәм хөкүмәтнең гаять зур игтибар бирүенә дә карамастан, 1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары авыл хуҗалыгы өлкәсендә партиянең Татарстан оешмасының канәгатьләнерлек эшләмәгәнлеген күрсәтәләр. 1939 нчы елны бөртекле ашлык уңышы буенча да, шулай ук техник культуралар уңышы буенча да дәүләт планы үтәлмәде.

Бу, барыннан да элек, безнең машина-тракторлар паркыннан тулысынча файдалана белмәвебез белән аңлатыла. 1939 нчы елны без трактор эшләре буенча еллык планны бары 77,3 процентка гына үтәдек. 103 МТС тан 17 МТС трактор эшләре буенча дәүләт планының яртысын да үтәмәделәр. Орденлы Актаныш МТСы, Теләнче Тамак, Нөркәй, Сарман, Тымытык, Мөслим, Столбище, Базарлы Матак һәм кайбер башка МТС лар кебек, дәүләт планын арттырып үтәгән алдынгы МТС лар белән бер рәттән, колхозлар белән төзелгән договорларны үтәүне өзгән һәм трактор эшләре буенча бөтен республика күләмендәге күрсәткечләрне юк дәрәҗәсенә китергән МТС лар да бар. Болар—Юртыш, Зөя, Юдино, Кызыл Чапчак, Рождественский, Константиновка МТС лары һәм күп кенә башка МТС лар.

(Дәвамы 2 нче биттә).

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ЭШЕ ТУРЫНДАГЫ ОТЧЕТТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. М. Алемасов доклады

(Дәвамы. Башы 1 нче биттә).

Агротехника чаралары планы үтәлмәде. 1938—1939 нчы елның кышында тирес чыгару планы бары 71 процентка гына, кар тоту планы 71 процетка гына үтәлде. 180 мең гектардан артык уҗым җирләренә янадан чәчү аркасында язгы чәчү 1 нче июньгә кадәр сузылды. Пар җирләрен сөрүне 15 нче июльгә генә тәмам иттек. Пар җирләрен культивацияләү планы бары 34,4 процентка гына үтәлде. Шулай ук без 100 процент белән сортлы орлыклар чәчү турында партиянең һәм хөкүмәтнең күрсәтмәләрен дә үтәмәдек.

Яхшы уңыш алуны оештыра белмәү белән бергә, без урып-җыюны да югары дәрәҗәдә үткәрә алмадык. Ул 10 нчы сентябрьгә кадәр сузылды, ә Питрәч, Тәмте, Югары Ослан, Алексеевский, Куйбышев, Юдино кебек кайбер районнарда урып-җыю октябрь ахрына кадәр тартылды. Бу хәл зур югалтуларга китерде. 1939 нчы елны игеннәрне урып-җыюның озакка сузылуы күп кенә районнарда көзге чәчүнең вакытында үткәрелмәвенә сәбәп булды.

Авыл хуҗалыгының хәзергә әле иң артта калган тармагы булган терлекчелеккә килсәк, безнең республикада бу яктан хәл түбәндәгечә тора. Отчет чоры эчендә Татарстан колхозларында җәмагат терлекчелеге мөгезле эре терлекләр буенча 16,8 процентка, атлар буенча 17,2 процентка, сарыклар буенча 27,9 процентка үсте. Ә инде барлык төрләрдәге барлык терлекләр буенча һәм республикадагы барлык хуҗалык категорияләре буенча булган саннарны алып карасак, бу чорда, атларны һәм сарыкларны санамаганда, терлекләр саны кимеде. Гомумән алганда, 1939 нчы елны республикабыздагы колхозларда һәм совхозларда терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планы үтәлмәде. Бу мәсьәләдә күп кенә колхозларда һәм совхозларда яшь терлекләрне саклау өчен көрәшнең гаят дәрәҗәдә йомшак баруы бик начар йогынты ясады. Һәрбер колхозда 3 терлекчелек фермасы булдыру муафик икәнлеге турында СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 8 нче июль күрсәтмәсе үтәлмәде. Яңа фермалар оештыру буенча ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм ТАССР Совнаркомы тарафыннан расланган план сан ягыннан да, терлекләр саны буенча да үтәлмәде.

1939 нчы елны терлек азыгы базасы булдыруга җир һәм совет органнарының карашын һич тә түзеп тора алмаслык хәл дип санарга кирәк. Силос салу планы бары 61,9 процентка гына, болыннар булдыру планы 46,5 процентка гына, аларны чистарту планы 22,4 процентка һәм төп алу планы 8 процентка гына үтәлде. Терлекчелекне үстерүгә бәйләнешле расходларга дәүләт җибәргән 8.279 мең сумнан бары 7.550 мең сумы гына, ягни 91,2 проценты гына файдаланылды. Терлекчелек төзелеше буенча гына да 426 мең сум файдаланылмыйча калды.

Партиянең Татарстан оешмасы „Колхозларның җәмагат җирләрен әрәм-шәрәм итүдән саклау чаралары турында“ СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 27 нче май карарын тормышка ашыру буенча зур эш үткәрде. 1938 нче елны хезмәткә яраклы 58.673 колхозчы бер генә хезмәт көне дә эшләмәгән булса һәм 218.651 колхозчының хезмәт көннәре 50 дән ким булган булса, 1939 нчы елны хезмәткә яраклы колхозчылардан 13.127 кеше генә бер хезмәт көне дә эшләмәде, ә билгеләнгән минимум хезмәт көннәреннән, ягни елына 80 нән ким хезмәт көннәре эшләгән колхозчылар 80.723 кеше булды.

Колхоз производствосында эшләмәүче яки бөтенләй диярлек эшләмәүче колхоз членнарының саны бик нык кимүгә дә карамастан, бу 93.850 кеше—әле бик зур сан. Партия оешмасы моңа җидди игтибар бирмичә кала алмый. Кайбер колхозларда хезмәт дисциплинасының торышы бик начар. Мәсәлән, Дөбъяз районының Сталин исемендәге колхозында колхозчыларның 30 проценты минимум хезмәт көннәрен эшләмәгән, Калинин районының „Кызыл Чишмә“ артелендә колхозчыларның 21,4 проценты минимум хезмәт көннәрен эшләмәгән, ә Чүпрәле районында хезмәткә яраклы колхозчылардан 5.242 кеше минимум хезмәт көннәре эшләмәгәннәр. Бу—бөтен составның кимендә 20 проценты дигән сүз.

Колхозчыларның, ялгыз хуҗалыкчыларның һәм колхоз члены булмаган башка хуҗалыкларның каралты тирәсе җирләрен үлчәү эше каралты тирәсе участкылары өчен билгеләнгән нормалардан тыш 33.709 гектар артык җир барлыгын күрсәтте. Бу артык җирләр, СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының югарыда әйтелгән карарына тулысынча туры китереп, кисеп алындылар. Сез беләсез, шул ук карар безне 1939 нчы елны хутор хуҗалыкларын авылларга күчереп утыртырга мәҗбүр иткән иде. Бөтен республикада 711 хутор хуҗалыгы бар иде, шулардан 503 хуҗалык билгеләнгән срокта күчерелде.

Татарстан республикасы колхозларын һәм совхозларын 1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерләү өлкәсендә җидди кимчелекләр бар. Тракторларга ремонт ясау планы әле һаман да төгәлләнмәгән, 5 нче мартка ремонт планы бары 71,3 процентка гына үтәлде. Тракторларга ремонт ясау буенча еллык планны бары 16 МТС кына үтәде. Шулардан Нөркәй МТС ы бу планны республикада беренче булып, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар көненә үтәде. Актаныш, Кама Тамагы, Теләнче Тамак, Тымытык, Теләче һәм башка кайбер МТС лар ремонтны срогыннан элек тәмам иттеләр. Ләкин тракторларга ремонтны начар алып баручы машина-трактор станцияләре дә бар. Мәсәлән, Карамалы МТС ы планны 40,8 процентка, Зайнский МТС ы 41,2, Зөя МТС ы 41,1, Тат. Ходяш МТС ы 44,7 процентка гына үтәгәннәр.

Кышкы агротехника чараларына бәя биреп җиткермәү әле һаман да дәвам итә. Тирес чыгару планы бары 62,3 процентка гына, кар тоту планы 76,4 процентка гына үтәлде.

Хәзер безнең машина тракторлар паркын механизаторлар кадрлары белән тәэмин итү мәсьәләсе тагын да зуррак әһәмият ала. Ләкин бу кадрларны хәзерләүнең барышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. 20 нче февральгә механизаторлар мәктәпләренә укучылар туплау планы бары 60,9 процентка гына, МТС ларның үзләрендәге тракторчылар курсларына туплау планы 82,1 процентка гына үтәлде. Алексеевский, Питрәч, Рождественский, Тирсә, Кичү, Чишмә һәм башка шундый МТС ларда эш бигрәк тә начар тора. Гади орлыкларны сортлы орлыкларга алмашуны төгәлләү турында ВКП(б) Өлкә Комитетының күрсәтмәсе үтәлмәде.

Республикабызның авыл хуҗалыгында мондый хәлне китереп чыгарган сәбәпләрне тикшереп карасак, без түбәндәгеләрне күрәчәкбез:

Беренчедән. Республикабыздагы күп кенә колхозлар һәм совхозлар кышкы һәм язгы агротехника чаралары планын үтәү буенча эшне гадәттән тыш начар үткәрделәр. Район җир органнары һәм МТС лар исә, колхозларга конкрет җитәкчелек итмәделәр, искечә җитәкчелек иттеләр, артта калучы колхозлардагы хәлне төзәтә алмадылар, аларны алдынгылар дәрәҗәсенә кадәр күтәрә алмадылар, югары иген уңышы алуны оештыра алмадылар.

Икенчедән. 1938—1939 нчы елның кышында тракторларга ремонт ясау планының үтәлмәве, ремонтның сыйфаты түбән булу, кыр шартларында техник яктан дөрес тәрбиянең булмавы—болар барсы да тракторлар паркының куәтеннән файдаланып җитмәүгә, трактор эшләренең үзенә төшү бәясенең кыйммәтләнүенә китерделәр.

Өченчедән. Хезмәтнең, хезмәткә түләүнең, бигрәк тә эш башыннан түләүнең начар оештырылуы, хезмәт дисциплинасының йомшак булуы авыл хуҗалыгы эшләрен үтәү срокларының озакка сузылуына сәбәп булды. 1939 нчы елның язында оештырылган звенолар, булышлык булмаганлыктан, күпчелек хәлләрдә таралдылар.

Дүртенчедән. Колхозчылар, МТС һәм совхоз эшчеләре арасында массовый-политик эш канәгатьләнерлек куелмады. Колхозчылар һәм совхоз эшчеләре арасында социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен оештыруга җитәкчеләр формаль төстә карадылар. Социалистик ярыш договорларының үтәлүен әледән-әле тикшереп тору булмады, авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашкан алдынгылар тәҗрибәсен популярлаштеру һәм үткәрү йомшак барды.

Бишенчедән. Район җир бүлекләренең һәм МТС ларның эшенә ТАССР Наркомземы һәм Совнаркомы канцелярияче-бюрократларча җитәкчелек иттеләр. Бу җитәкчелек бик күп хәлләрдә сукыр килеш алып барылды, эшне һәм колхоз производствосында бара торган үзгәрешләрне белеп тору булмады. Татарстан Наркомземының һәм Совнаркомының кайбер җаваплы работниклары күп кенә мәсьәләләрдә үзләрен политик җитәкчеләр итеп күрсәтмәделәр, бәлки артта калган настроениеләр койрыгында сөйрәлүче кешеләр итеп күрсәттеләр.

Алтынчыдан. ВКП(б) райкомнары практикасында бик күп хәлләрдә бөтен эшне җир һәм совет органнары өчен үзләре эшләргә тырышу күренә. Бу хәл шуңа китерә ки, колхозларга турыдан-туры җитәкчелек итәргә тиеш булган җир һәм совет органнары читтә калалар, аларның җаваплылыгы кими. Ә партия райкомнары, агымдагы эшләргә күмелгәнлектән, дөрес анализ ясарлык һәм колхоз төзелеше практикасын тупларлык хәлдә булмыйлар, артталыкны бетерү буенча нәтиҗәле чаралар күрерлек һәм башкарма комитетның, район җир бүлегенең, МТС ларның һәм совхозларның эшенә юнәлеш бирерлек хәлдә булмыйлар.

Шушындый ук ялгышлар бер үк дәрәҗәдә партиянең Өлкә Комитеты эшендә дә бар. Өлкә Комитеты авыл хуҗалыгына җитәкчелек итү буенча райкомнарның эшен тиешенчә оештыра алмады.

Ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерү турында, техник культуралар уңышын уртача 30—35 процентка арттыру турында, терлекләр санын арттыру турында партиянең XVIII нче съезды карарларын, бөек Сталин күрсәтмәләрен уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен көрәштә партиянең Татарстан оешмасы түбәндәге чараларны үткәрергә тиеш:

1. Партия һәм хөкүмәт күрсәтмәләренә тулысынча туры китереп, җир органнарын үзгәртеп кору эшен иң якын араларда төгәлләргә, аларны эштә тикшерелгән һәм партиябезгә чын күңелдән бирелгән, авыл хуҗалыгы эшен алга алып барырга сәләтле булган кешеләр белән ныгытырга.

2. Алдагы язгы чәчүгә хәзерлекне большевикларча оештырырга, моның өчен якын көннәрдә үк тракторларга һәм тагылма машиналарга ремонтны төгәлләргә, ремонтның сыйфатын тикшерергә һәм 1940 нчы елны барлык машина-трактор паркының төгәл һәм тоткарсыз эшләвенә ышанган булырга кирәк. Ягулыкны тулысынча хәзерләргә. 1940 нчы елны бер генә трактор да, бер генә комбайн да квалификацияле йөртүчесез калмасын өчен механизаторлар кадрлары хәзерләү планын үтәргә. Партиянең авылдагы бөтен оешмасын югары иген уңышы алу эшендә хәл иткеч чара булган кышкы һәм язгы агротехника чараларының бөтен комплексын тормышка ашыруга тупларга кирәк. Колхозларның үз эчләрендә чәчүлек орлыклары ресссурсларын туплау исәбенә чәчү планын үтәү өчен орлыклар белән тәэмин итәргә. Җанлы тарту көчен механик тарту көче белән дөрес итеп бергә кушарга кирәк.

3. Барлык колхозларда хезмәтне даими эшләүче звенолар төзү нигезендә оештырырга, аларга барлык чаралар белән булышлык итәргә. Колхоз производствосы өчен һәрбер колхозчының җаваплылык хисен хезмәтне звенолап дөрес оештыру гына тудыра ала икәнлекне, ефремовча агротехниканы практик рәвештә үзләштерү генә аларны югары уңыш алуга оештыра ала икәнлекне, бик нык истә тотарга кирәк.

4. Бөтен район күләмендәге күрсәткечләрне артта калучы берничә колхоз киметә дигән сылтаудан туктарга, бәлки аларда эшне большевикларча оештырырга һәм аларны алдынгылар дәрәҗәсенә кадәр күтәрергә кирәк.

5. 1940 нчы елны МТС ларның һәм совхозларның барлык тракторларыннан һәм комбайннарыннан файдалануны бик нык яхшыртырга кирәк. Язгы чәчүне, урып-җыюны һәм авыл хуҗалыгы эшләренең башка төрләрен югары дәрәҗәдә, яхшы һәм отличное сыйфат белән үткәрергә. Ягулыкка һәм запас частьләргә бик нык экономия ясап, 1940 нчы елны трактор эшләре буенча Татарстанның яңадан беренчелек алуына ирешергә кирәк.

6. Район җир бүлекләренең, МТС ларның һәм Наркомземның колхозларга агрономия хезмәте күрсәтүләрен җидди рәвештә яхшыртуга ирешергә. 1940 нчы елны гектарыннан кимендә 13 центнер бөртекле ашлык һәм Чувашстан, Мордовия республикалары белән төзелгән социалистик ярыш договоры буенча алынган йөкләмәләрдән дә ким булмаган күләмдә техник культуралар уңышы алуга ирешергә кирәк.

7. Терлекчелекне үстерүдәге артталыкны бетерергә. Барлык җир, совет һәм партия органнары работникларының бу тармакка игтибарын көчәйтергә, 1940—1941 нче елны терлекләрне җылы биналарда һәм көр тоту өчен терлекчелек төзелешен һәм терлек азыгы базасы булдыруны большевикларча оештырырга.

8. Социалистик ярышны оештыруга һәм стахановчылык хәрәкәтен үстерүгә бюрократларча формаль карауны бетерергә. Барлык колхозларның, совхозларның һәм МТС ларның, барлык колхозчыларның һәм авыл хуҗалыгы работникларының социалистик ярыш белән чолганып алынуларына ирешергә. Ярыш буенча договор йөкләмәләренең үтәлүен әледән-әле тикшереп торырга. Авыл хуҗалыгы алдынгыларын барлык чаралар белән кызыксындырырга, аларның тәҗрибәсен киң популярлаштерергә, бу тәҗрибәне массовый күләмдә үзләштерергә. Колхоз һәм совхоз производствосын өзүче ялкауларга һәм җебегәннәргә рәхимсез удар ясарга кирәк.

ВКП(б) ның авыл райкомнары аңларга тиешләр: уңышлар һәм җиңүләр бары тик партия оешмасы колхозчылар массасы арасында, совхоз һәм МТС эшчеләре арасында, җидди политик эш җәеп җибәргәндә генә, аларны коммунистик тәрбияләү өстендә, аларның гомуми культура дәрәҗәсен күтәрү өстендә өзлексез эшләгәндә генә тәэмин ителәчәкләр. Бурыч, 1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә—колхоз җиңүләренең Бөтенсоюз смотрында катнашу хокукы алу өчен бара торган ярышка җитәкчелек итүдән гыйбарәт.

III. СӘҮДӘ ҺӘМ ФИНАНС

Отчет чоры эчендә ваклап сәүдә итү челтәре 1937 нче ел белән чагыштырганда 964 единицага яки 20,4 процентка, җәмагат туклануы челтәре—55 единицага яки 10,8 процентка үсте. Бу үсеш һәм шулай ук оборот сумасының артуы сәүдәдә һәм җәмагат туклануында эшне җидди төстә яхшыртырга тиеш кебек иде. Ләкин бу юк, чөнки сәүдә оешмаларының һәм шулай ук җәмагат туклануы оешмаларының җитәкчеләре үзләренең эшләрен фондлы товарларны исәпкә алып кына төзиләр, үзәкләштерелмәгән төстә сатып алуларны оештыруда кирәкле инициативаны күрсәтмиләр.

Дәүләт һәм кооператив акчаларын туздырулар һәм урлаулар күп санда булу—сәүдә оешмалары эшендәге бәләләрнең берсе. Татсоюзда гына да акча туздыруларның һәм урлауларның 4.570 мең сумга җиткәнлеген күрсәтеп узу гына да җитә.

Партиянең күп кенә оешмалары сәүдә оешмалары эшеннән читтә торганлыктан, сәүдә-кооперация кадрлары арасында политик-тәрбия эшен тиешенчә алып бармаганлыктан, сәүдә эшен яхшыртуга, халыкка культуралы хезмәт күрсәтүгә аларны оештырмаганлыктан, сатып алучыларга ким үлчәп бирүләр, алар белән тупас эш итүләр, хезмәт ияләренең сорауларын искә алырга, аларның сорауларын канәгатьләндерүгә ирешергә теләмәү шушы вакытка кадәр урын алып килә.

Бу кимчелекләрне бетерү, сәүдә-кооператив органнарының эшен тагын да югары дәрәҗәгә күтәрү, барлык эчке ресссурсларны туплау өчен, җирле промышленность һәм промкооперация предприятиеләрендә киң куллану товарлары эшләп чыгаруны оештыру өчен җаваплылык хисен күтәрү—партия оешмаларының әһәмиятле бурычы.

Финанс эше өлкәсендә күрнеш түбәндәгечә: 1937 нче елны Татарстан республикасының бюджеты 318,2 миллион сум булган булса, 1939 нчы елны ул 393 миллион сум булды. 1940 нчы елга бюджет 410 миллион сумлык итеп планлаштырылды. Бюджетның күп өлеше социаль-культура чараларына юнәлдерелеп килде һәм юнәлдерелә. Мәсәлән, 1940 нчы елны бу расходлар бөтен бюджетның 71,3 процентын тәшкил итәләр. Бу—формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булган культураны үстерү турында партиянең һәм хөкүмәтнең гаят зур кайгыртучанлык күрсәтүен ачык чагылдыра. Ләкин шуны күрсәтеп үтәргә кирәк: җирле промышленность наркоматларының (мин бу турыда югарыда әйттем инде) һәм коммуналь предприятиеләрнең гаебе буенча 1939 нчы елны без бюджетыбызга 6 миллион сумнан артыграк акча алып җиткермәдек. Наркомфин һәм аның органнары начар эшләүче наркоматларга һәм предприятиеләргә карата сум белән контроль ясау буенча тиешле чаралар күрмәделәр, хуҗалык исәбен ныгыту өчен көрәшмәделәр. Безнең финанс органнары ялгыз хуҗалыкчылар тарафыннан налог йөкләмәләрен түләмәү фактлары белән әле һаман да килешәләр. Чүпрәле, Беренче Май һәм Буденный районнарында бу эш бигрәк тә начар.

IV. СОВЕТ ҺӘМ КУЛЬТУРА ТӨЗЕЛЕШЕ

РСФСР һәм Татарстан АССР Верховный Советларына, шулай ук хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларны оештыру һәм үткәрү—отчет чоры эчендә партиянең Татарстан оешмасы эшендәге гаят зур политик йомгакларның берсе.

Сайлауларда сайлаучыларның 98,8 проценты катнашты. Сайлауларда катнашучыларның 99,1 проценты коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына тавыш бирде.

Советларга сайлауларда коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы яңа гүзәл җиңүгә иреште. Сайлаулар совет халкының бөек мораль-политик бердәмлеген, Ленин—Сталин партиясенә аның чын күңелдән бирелгәнлеген һәм мәхәббәтен күрсәттеләр.

Хәзер, Совет дәүләт аппаратының барлык буыннары Сталин Конституциясе нигезендә сайланганнан соң, безнең алдыбызда шушындый бурыч тора,—ул, совет органнарының эшен үзгәртеп коруны төгәлләүне оештыру. Советларның эшендә һәрбер депутат актив катнашырга тиеш. Советларның беренче сессияләрендә оештырылган даими комиссияләрнең һәм барлык депутатларның планлы эшләүләре, сайлаучылар алдында югары дәрәҗәдә җаваплылык хис итүләре, хәзер безнең дәүләтебезнең ил эчендәге төп бурычы—хуҗалык-оештыру һәм культура-тәрбия буенча тыныч эштән гыйбарәт булуы турында ВКП(б) ның XVIII нче съездында иптәш Сталин биргән күрсәтмәне һәр вакыт исләрендә тотулары кирәк. Партия оешмасының бурычы—барлык депутатларга, совет аппаратының барлык работникларына политик тәрбия бирүне юлга салу, аларны көн саен өйрәнеп тору, үзләрен актив, алдынгы работниклар итеп күрсәткән кешеләрне югары постларга кыюлык белән күтәрү.

Аннары иптәш Алемасов суд һәм тикшерү органнарының эше турындагы мәсьәләләргә күчеп, аларның эшендә отчет чорында бик күп кимчелекләр, ялгышлар һәм хәтта бозулар да булганлыгын әйтә.

Күп кенә работникларның җансызлыгы һәм политик сукырлыгы нәтиҗәсендә бу органнарга дошман элементлар үтеп керә алдылар. Бу хәл совет законнарын һәм суд-тикшерү эшләрен алып бару методларын бозуда күренде.

Мәсәлән, Әгерҗе районының халык суды, партия район комитетының игтибарсызлыгыннан һәм җансызлыгыннан файдаланып, районындагы 49 колхозның 44-н суд җаваплылыгына тарта алган. Шуның белән бергә бу колхозларның кайберләре суд җаваплылыгына берничә тапкыр тартылганнар. Судья Мостафин суд утырышларында гаепләүләрнең дөреслеген расларлык документлар таләп итмәгән, эшләрне җавап бирүчеләрдән башка тыңлаган, халык судларының карарларын рәсмиләштермәгән, халык утырышчыларына аларны кул куярга бирмәгән. Ул гына да түгел, Мостафин суд рөхсәтеннән башка суд башкаручыларына башкару кәгазьләрен тапшырган.

Партия Өлкә Комитеты Мостафинның эшен революцион законлылыкның дәрәҗәсен төшерергә юнәлдерелгән провокацион эш дип карады. Мостафин эшеннән алынды һәм партиядән чыгарылды.

Шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк: шуннан 4—5 ай элек Әгерҗе районының халык судын Наркомюст тикшергән булган, ләкин аның вәкилләре Мостафинның һәм судның эшендә гомумән бернинди кимчелекләр тапмаганнар.

Партия Өлкә Комитетының зур гаебе шуннан гыйбарәт: кайбер суд һәм тикшерү органнарының җитәкче работникларының үз-үзләрен шикле тотулары турындагы мәсьәләне күп кичегеп куйды, ә бу органнар тарафыннан җибәрелгән бөгелешләрне һәм бозуларны төзәтүгә партия Өлкә Комитеты бары тик партиябезнең Үзәк Комитеты күрсәткәннән соң гына керешә.

Хәзер суд һәм тикшерү органнарында эш шактый тәртипкә салынды, ләкин кимчелекләр әле зур һәм аларны бетерү өчен күп һәм җидди эшләргә кирәк.

* * *

Партиянең XVIII нче съезды карарларында илебез үсешенең хәзерге этапында төп игтибар коммунистик тәрбия мәсьәләләренә, хезмәт ияләренең аңында капитализм калдыкларын бетерүгә юнәлдерелә диелгән. Бу тарихи бурычны хәл итүдә халык мәгарифе, культура-агарту учреждениеләре органнарының эше гаят зур әһәмият ала.

Республикабызның халык мәгарифе органнарының эшендә отчет чоры эчендә күп кенә үзгәрешләр булды. Мәктәпләр саны 1937 нче ел белән чагыштырганда 174 кә—5,2 процентка, ә укучылар саны 57.127 кешегә—11,4 процентка үсте. Безнең мәктәпләрдә укучыларның 51 проценты татарлар, 42 проценты руслар, 7 проценты башка милләт вәкилләре. Урта мәктәпләр саны 77,9 процентка, ә аларда укучылар саны 62,6 процентка үсте.

Ләкин республикабызның халык мәгарифе органнары шәһәрдә гомуми урта белем бирү бурычын әле башкармадылар һәм авылда гомуми 7 еллык белем бирүне тормышка ашырудан бик ерак торалар. Ул гына да түгел: 60 районнан алынган саннарга караганда, 1939—40 нчы уку елында мәктәп яшендәге 7.434 бала укуга тартылмаган. Мәктәпләребездә укытуның сыйфаты да түбән булуда дәвам итә. 34 районнан алынган саннарга караганда, шушы уку елының икенче чирегендә өлгерүчәнлек бары 74,9 процент кына, ә Казанда—72,2 процент кына булган.

Рус мәктәпләре булмаган мәктәпләрдә рус теле буенча өлгерүчәнлек бик начар тора. Наркомпрос татар мәктәпләрендә татарлардан рус теле укытучылары кадрлары хәзерләү һәм аларны яңадан хәзерләү бурычын башкара алмады. Гомумән, педагогия кадрлары хәзерләү Наркомпрос эшендә бик йомшак урын булып тора.

1939 нчы елның 1 нче январена булган саннарга караганда, безнең республикада 177,8 мең укый-яза белмәүче кеше бар иде. 1939 нчы елны 63 мең кеше укытылды, ә хәзер бары 23.154 кеше генә укытыла. Аз укый-яза белүчеләрне укыту эше дә яхшыдан түгел: аз укый-яза белүче 122 мең кешедән бары 31 мең кеше генә укытыла.

Отчет чоры эчендә республикабызда политик-агарту учреждениеләренең челтәре үсте, аларның эш эчтәлеге беркадәр яхшырды. Бездә художество үзешчәнлеге түгәрәкләренең саны 2.800 дән артык булуын күрсәтеп үтү генә дә җитә. Күп кенә районнарда (Дөбъяз, Мамадыш, Лаеш, Чепья һәм башка районнар) культура йортлары, клублар һәм уку өйләре, культура-агарту эше үзәкләре булып әвереләләр. Ләкин культура учреждениеләре халыкның үскән сорауларын канәгатьләндерә алсыннар өчен партия оешмалары әле күп эшләргә тиешләр.

1939 нчы елны Татарстанда укытучыларның белемен күтәрү институты, укытучылар өчен ике институт, татар теле һәм әдәбияты буенча фәнни тикшеренү институты оештырылды.

Отчет чоры эчендә Татарстанда югары белем алу эше шактый алга китте. Студентлар саны артты, шуның белән бергә, татар студентлары санының 1.060 кешедән 1.702 кешегә кадәр, ягни 60 процентка үскәнлеген, өлгерүчәнлекнең күтәрелгәнлеген, канәгатьләнмәслек билгеләрнең шактый кимегәнлеген аеруча яхшы күрнеш дип санарга кирәк. Ләкин студентлар арасында политик-тәрбия эшенең йомшак куелуын җидди кимчелек итеп күрсәтергә кирәк.

Отчет чоры шулай ук сәнгатьнең, бигрәк тә милли сәнгатьнең тагын да үсүе белән характерлана. Татар опера театры эшли башлады һәм ныгый бара. Ул татарча ике опера куйды инде. Халык җырларын һәм биюләрен башкару буенча күп кенә ансамбльләр төзелде. Шуның белән бергә безнең алдынгы ансамблебез РСФСР да икенче урынны алды. Чистайда балалар өчен музыка мәктәбе оештырылды. 40 колхозда беренче тапкыр буларак тар пленкалы һәм тавышлы киноустановкалар эшли башлады. Ләкин бездә әле колхоз-совхоз театрлары бик аз һәм аларның эш сыйфаты гаят түбән. Радиолаштыру эше начар тора. Шәһәрдәге һәр йөз кешегә 4,6 һәм авыл

(Дәвамы 3 нче биттә).

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ЭШЕ ТУРЫНДАГЫ ОТЧЕТТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. М. Алемасов доклады

(Ахры. Башы 1 нче һәм 2 нче битләрдә).

җирендә бары 0,45 кенә радиоточка туры килә.

Матбугатка сорауның елдан-ел һәм айдан-ай үсеп баруы—республикабыздагы хезмәт ияләренең культура дәрәҗәсе күтәрелүнең гаять зур күрсәткече. Татарстанда хәзер 145 газета һәм 10 журнал чыгарыла, аларның яртысы татар телендә. Безнең газеталарның разовый тиражы 499.600 данә.

Безнең матбугатыбызның идея-политик дәрәҗәсе шактый күтәрелде, ләкин газеталарның эшендә кимчелекләр әле һаман да күп. Басылып чыга торган материалларның нәтиҗәлелеге өчен көрәшнең йомшак булуы, редакциядән тыш актив белән эшләүнең җитәрлек булмавы—аларның эшендәге бигрәк тә түзеп тормаслык кимчелек.

Сәламәтлекне саклау өлкәсендәге чаралар да халыкка культура-көнкүреш хезмәте күрсәтү үсүенең җидди күрсәткече булып тора. Отчет чоры эчендә сәламәтлек саклау бюджеты 56,6 миллион сумнан 68,5 миллион сумга кадәр үсте. Бу хәл дәвалау һәм профелактика учреждениеләре челтәрен киңәйтүне тәэмин итте. Больницалардагы койкалар саны 1.222 гә, фельдшерлык - акушеркалык пунктлар саны 77 гә, врачлык амбулаторияләре саны 7 гә, даими яслеләр саны 47 гә үсте. Ләкин дәвалау һәм бигрәк тә профелактика эше гаят начар куелган. Татарстан Наркомздравы һәм аның җитәкчеләре еш кына практик эш урнына лыгырдау белән шөгылләнәләр.

Күп кенә совет һәм партия оешмалары җитәкчеләренең сәламәтлек саклау эшеннән читтә торуларын, аңа җитәкчелек итмәүләрен, медицина работникларына кирәкле ярдәм күрсәтмәүләрен, медицина кадрларын дөрес урнаштыру, аларга игтибар белән карау өчен көрәшмәүләрен икрар итәргә кирәк.

Иптәш Алемасов коммуналь хуҗалык органнарының эшенә тулы характеристика бирә. Соңгы елларда Татарстан наркомына гына караган торак - коммуналь хуҗалык төзелешенә 39,3 миллион сум бирелгән. Ләкин соңгы вакытларга кадәр бу тармакта әле зур гына кимчелекләр яшәп килә. Ә коммуналь эш җитәкчеләре үзләренең начар эшләүләрен аклау өчен объектив сәбәпләр эзлиләр.

V. ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Отчет чоры эчендә партиянең Татарстан оешмасының һәм аның җитәкче органнарының ныгуы аның составын тәртипкә салу юлы белән, ышанычсыз, дошман һәм чит элементларны партиядән куу, аның сафларына эшчеләрдән, колхозчылардан һәм интеллигенциядән булган иң яхшы вәкилләрне сайлап алу юлы белән барды. Бу эш политик гамсезлекне бетерү һәм коммунистларның революцион уяулыгын тагын да күтәрү юлы белән; бөтен партия тормышының идея-политик дәрәҗәсен күтәрү, партия, совет һәм хуҗалык оешмаларына җитәкче постларга партиябезгә чын күңелдән бирелгән яңа кадрларны кую юлы белән; партия оешмасының киң катлау хезмәт ияләре массасы белән элемтәсен ныгыту һәм тагын да киңәйтү юлы белән барды. Болар барсы да партия оешмасының үсүендә аеруча ачык чагылдылар: партиянең XIX нчы Өлкә конференциясендә ВКП(б) членнарыннан 12.646 кешедән һәм 6.361 кандидаттан вәкилләр килгән булса, бу конференциядә инде 20.560 членнан һәм 15.026 кандидаттан вәкилләр килде. Ягни партия оешмасы 87,9 процентка үсте.

Хезмәт төре ягыннан алганда оешманың составы турындагы саннар түбәндәгеләрне күрсәтәләр: турыдан-туры производствода эшләүче эшчеләр саны 50,8 процентка үскән булса, хезмәткәрләр саны 87,5 процентка, колхозчылар 130 процентка үстеләр. Бу саннар кайбер райкомнарның партиягә кабул итү эшен тәртипкә салмаганлыкларын, ВКП(б) сафларын беренче чиратта промышленностьта, һәм авыл хуҗалыгында җитәкче профессия кешеләре исәбенә үстермәгәнлекләрен күрсәтәләр. Ул гына да түгел, күп кенә райкомнар партиягә сайлап алуда Ленин—Сталин принципларын боздылар, партиягә кабул итүгә еш кына игтибарсыз карадылар. Нак менә шуңа күрә дә ВКП(б) Өлкә Комитеты 1939 нчы елны гына да партия оешмасын үстерү мәсьәләләре буенча берничә карар кабул итәргә мәҗбүр булды.

Ләкин бу мәсьәлә буенча ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм Өлкә Комитетының күп тапкырлар бик тулы күрсәтмәләр бирүләренә дә карамастан, кайбер райкомнар әле һаман да кабул итү мәсьәләләренә бик гаҗәп төстә карыйлар. ВКП(б) ның Кайбыч райкомы бюросы үзенең шушы елның 17 нче февралендә булган утырышында милициядә эшләүче И. дигән бер кешенең партиягә кабул итүне сорап биргән гаризасын тикшергән. Протоколда язылуынча, аның бер агасы бетерелгән, икенчесе репрессияләнгән, кайнатасы кулак, И. аның белән элемтә тота, һәм бу кулак 5 елга иркеннән мәхрум ителүгә хөкем ителгән. Утырышта И. не ВКП(б) сафларына кабул итәргә дип такдим кергән. Нигез менә мондый: әгәр партиягә алмасаң аны милиция органнарында калдырырга ярамый. Райком бюросы И. не партиягә алган. Бу факт үзе генә дә кайбер җитәкчеләрнең әле иптәш Сталин әйткәнчә партия ишегенең бары тик партия интересларын ахрынача яклый алырлык иң яхшы һәм иң лаеклы кешеләр өчен генә ачык булырга тиешлеген аңламаганлыкларын күрсәтә.

Отчет чоры эчендә партиянең Татарстан оешмасы, XVIII нче съезд карарларына һәм ВКП(б) уставына тулысынча туры китереп, партия органнары аппаратын үзгәртеп корды. Партия райкомнарында һәм шәһәр комитетларында яңа бүлекләр—кадрлар бүлеге, оештыру - инструкторлык бүлеге, хәрби бүлек төзелде. Шундый ук бүлекләр ВКП(б) Өлкә Комитетында да төзелделәр.

Партия аппаратын үзгәртеп кору партия эшенең бөтен эчтәлеген яхшыртуга, партиянең башлангыч оешмаларына ВКП(б) райкомнарының һәм шәһәр комитетларының җитәкчелеген көчәйтүгә куәтле этәргеч булып хезмәт итте. Партия органнарына булган соңгы сайлаулар турындагы саннар да партиянең эчке эшенең бөтен эчтәлеге яхшырганлыкны ачык күрсәтәләр.

Партиянең башлангыч оешмаларындагы отчет-сайлау җыелышларында барлык коммунистларның 97,3 проценты катнашты. Шуның өстенә җыелышларда катнашучыларның 56 проценты фикер алышуларда чыгып сөйләде. Үткән сайлауларда партиянең башлангыч оешмаларының 63 процентында җитәкче органнарның эше канәгатьләнерлек түгел дип табылган иде, хәзер бу процент 26,2 гә төште.

Безнең партия оешмасында коммунистларның язмышы өчен җаваплылык хисе бик нык күтәрелде. Хәзер партия оешмалары үз сафларының чисталыгы өчен көрәшеп, ышанычсыз һәм дошман элементлардан арынып, партиядән чыгару мәсьәләләренә уйлабрак һәм җиддиерәк якын киләләр, карарларны бары тик коммунистларга карата куелган гаепләүләрне җентекләп тикшергәннән соң гына кабул итәләр.

Ләкин бу мәсьәләдә инде бездә тулы тәртип урнаштырылды дип санау бөтенләй ялгыш булыр иде. Ялгышлар күп ясала әле. 1939 нчы елны райкомнар һәм шәһәр комитетлары партиянең башлангыч оешмаларының партиядән чыгару турындагы карарларының 39,7 процентын юкка чыгардылар, ә Өлкә Комитеты партиядән чыгару турында райкомнар һәм шәһәр комитетлары раслаган карарларның 24,3 процентын юкка чыгарды. Өлкә Комитетының да ялгышлар эшләгәнлеген әйтергә кирәк. Мәсәлән, 1939 нчы елны бюро 461 кешене ВКП(б) дан чыгаруны раслады. ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Партия Контроле Комиссиясенең партколлегиясе карарлары нигезендә Өлкә Комитетының 12 карары үзгәртелде.

Партиянең эчке эшенең торышы яхшыру нинди булса да тынычлану һәм гамсезләнү өчен һич тә нигез бирми. Партиянең башлангыч оешмаларының 26,2 процентында һәм партиянең район оешмаларының 18,6 процентында җитәкче органнарның эше канәгатьләнерлек түгел дип табылган булу факты әле күп кенә кимчелекләр һәм тәртипсезлекләр барлыкны күрсәтә. Партиянең кайбер райкомнары һәм кайбер башлангыч оешмалар, ә беренче чиратта аларның җитәкчеләре ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларыннан үзләренә барлык нәтиҗәләрне ясамаганнар. Бу, мәсәлән, Чистай райкомына кагыла. Бу райком партия эшен үзгәртеп коруны формаль төстә генә үткәргән, канцеляриячелек һәм эшне үз агымына кую элементларын бетермәгән. Кабул ителгән карарларның һәм югаргы оешмалар карарларының үтәлешенә контроль алып бару юлга салынмаган. Чистай оешмасында тәнкыйт һәм үзеңне тәнкыйтьләү эше соңгы вакытларга кадәр начар торган, шуның аркасында партия һәм совет работникларының җитәкче өлеше арасында тынычлану, гамсезлек һәм масаю хөкем сөргән. Райком, партиянең башлангыч оешмаларына, бигрәк тә авыл оешмаларына гаят начар җитәкчелек иткән. „Доброволец" һәм „Борьба за урожай" колхозлары партоешмаларында партиянең эчке эше һәм массовый-политик эш җимерелүгә кадәр китереп җиткерелгән, райком исә бер нинди дә чара күрмәгән.

ВКП(б) ның Чистай райкомында эшнең мондый хәлдә торуы—турыдан-туры, анда коллегиальностьның булмавы, партиянең эчке демократиясенең бозылуы нәтиҗәсендә килеп чыккан. Партиянең эчке демократиясен бозу фактлары ВКП(б) ның башка кайбер райкомнарында да булды. Мәсәлән, 1939 нчы елны Кайбыч райкомы бары ике генә, Зеленодольский шәһәр комитеты, Аксубай һәм Заинский райкомнары бары өчәр генә пленум үткәргәннәр, ә Югары Осланда 1939 нчы елның 10 нчы июненнән 1940 нчы елның 1 нче январена кадәр, ягъни 7 ай эчендә ВКП(б) райкомы пленумнары бер тапкыр да чакырылмаган. ВКП(б) ның Куйбышев райкомы бюросы 1938 нче елгы сайлаулардан бирле үзенең эше турында пленумга яки җыелышка отчет ясамаган. Бу оешмада тәнкыйт һәм үзеңне тәнкыйтьләү гадәттән тыш йомшак җәелдерелгән, райкомның аерым членнарының һәм бигрәк тә аның элекке секретаре иптәш Жарковның политик уяулыклары тупаслану фактлары булган.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы" басылып чыгу уңае белән партия пропагандасының куелышы турында" ВКП(б) Үзәк Комитетының тарихи карарын үтәү йөзеннән партиянең Татарстан оешмасы җитәкчелекне үзәкләштерү һәм бөтен пропаганда эшен үзгәртеп кору буенча зур эш эшләде. Безнең партия, совет, хуҗалык, комсомол кадрларыбызның, интеллигенция кадрларының күпчелегендә теориядән тәм табу туды, үзләренең көчләренә һәм марксизм - ленинизм теориясен беренче чыганаклар буенча үзлегеңнән уку юлы белән үзләштерергә сәләтле булуларына ышаныч ныгыды. Тулы булмаган саннарга караганда, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" н 70 меңләп кеше өйрәнә, шулардан 21.958 кеше партия членнары һәм кандидатлары. Шул вакыт эчендә ВКП(б) Өлкә Комитеты янында төзелгән лекторлар группалары көче белән, шулай ук ВКП(б) Өлкә Комитетының, Шәһәр Комитетларының һәм райкомнарның штаттан тыш лекторлары көче белән 3.297 лекция укылды, боларны 380 меңнән артык кеше тыңлады.

ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә „Красная Татария" 97, „Кызыл Татарстан" 91, „Херле Йалав" 76 мәкалә басып чыгардылар. Радио буенча 114 лекция һәм консультация укылды. Шулай булса да әйтергә кирәк, безнең өлкә газеталары партияле һәм партиясез большевикларның үсеп бара торган сорауларын канәгатьләндереп бетермиләр әле, пропагандистлык эше тәҗрибәсен тупламыйлар һәм популярлаштермиләр, партия пропагандасына партиянең кайбер район һәм башлангыч оешмаларының начар җитәкчелек итүләрен һич тә җитәрлек тәнкыйт итмиләр. Бу вакыт эчендә „Кызыл Татарстан" урындагы лекторларның бер генә лекциясен дә урнаштырмады.

Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин таглиматын үзлегеңнән өйрәнү күнекмәләре булу, билгеле, түгәрәкләр санының бик нык кимүенә китерде: ВКП(б) Үзәк Комитеты карарына кадәр 1.794 түгәрәк эшләгән булса, хәзер бары 350 түгәрәк кенә бар. Ләкин без әле кадрларыбызның һәм беренче чиратта партия, совет, хуҗалык оешмаларындагы җитәкче кадрларыбызның марксизм - ленинизм таглиматын үзләштерү өстендә барсының да күңел биреп эшләүләренә ирешә алганыбыз юк. Бу эшнең гаят әһәмиятле икәнлеген төшенмәгән, өйрәнмәүче, теоретик яктан үзләрен үстермәүче коммунистлар аз түгел әле. Лаеш район прокуроры иптәш Масленков үзенең теоретик белемен арттыру өстендә бөтенләй эшләми. Ул болай дип фикер йөртә: „Мин республика прокурорының приказларын укыйм, алар да марксизм - ленинизм нигезләреннән килеп чыгалар бит". (Көлү). Бездә андыйлар күп әле.

Партиянең күп кенә райком секретарьлары марксизм-ленинизм пропагандасы куелышына гаят дәрәҗәдә гамсез карыйлар, бу эшкә көндәлек җитәкчелек итмиләр. Ул гына да түгел, шундый секретарьлар бар, алар „вакыт булмау", „эш белән күмелгән булу" сылтавы астында үзләре дә укымыйлар, үсмиләр. Республика оешмалары работникларының да кайберләре шулай эшлиләр. Шулардан җир эшләре халык комиссары иптәш Черзорны, мәгариф эшләре халык комиссары урынбасары иптәш Мөэминовны, Татарстан Халык Хуҗалыгы Учеты Идарәсе җитәкчеләреннән берсе булган иптәш Кадыйровны һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин. Үзеңнең теоретик укуыңны оештыру эшенә партиячә караш булганда бик күп нәрсәләргә ирешергә мөмкин икәнлеге исбат ителде бит. Моны раслау өчен ВКП(б) ның Арча райкомы секретаре Бәдерттинев, ВЛКСМ ның Столбище райкомы секретаре Байцеров, партиянең Мамадыш район оешмасыннан мәктәп директоры булып эшләүче Гришин иптәшләрне китерергә мөмкин. Бу кешеләр ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын дөрес аңлаганнар, үзләренең теоретик белемнәрен һәр вакыт күтәрә торалар һәм эштә җидди уңышларга ирешәләр.

Агитация-масса эшен яхшырту өчен отчет чоры эчендә безнең партия оешмасы күп эш эшләде. ВКП(б) ның XVIII нче съезды материалларын аңлату эшендә 25.256 агитаторның эшләгәнлеген генә күрсәтеп үтү дә җитә. Ләкин агитация эше өлкәсендә дә бездә күп кенә кимчелекләр бар әле. Партиянең кайбер оешмалары агитация эшендә ирешелгән уңышларны ныгытып калмадылар, ә кайбер җирләрдә бу эшне бөтенләй туктаттылар. Бу—агитациягә бездә әле еш кына тиз үтеп китә торган кампания дип карыйлар, аның бөтен көченә бәя биреп җиткермиләр дигән сүз.

⁂

Аннары докладчы Татарстан комсомол оешмасының хәленә тулы анализ ясый.

Ул үзенең эшен шактый яхшыртты. 1939 нчы елны алдынгы яшьләрдән ВЛКСМ сафларына 42.807 кеше кабул ителде. Хәзер республикабызның комсомол оешмасы составында 108.836 кеше бар. Шул ук чор эчендә 679 урында башлангыч комсомол оешмасы төзелде. Комсомол рекомендациясе буенча без ВЛКСМ членнарыннан 6.742 кешене ВКП(б) сафларына кабул иттек.

Комсомол оешмалары хәзер дәүләт һәм хуҗалык эшендә катнашудан читләшмиләр инде. ВЛКСМ ның башлангыч һәм район оешмаларының хуҗалык бурычларын хәл итүдә үзләренең көндәлек катнашулары белән бик әһәмиятле һәм җидди мәсьәләләр күтәрүләрен күрсәтә торган мисальләр күп. Ләкин һәрбер колхозда комсомол оешмасы төзү турында ВЛКСМ Үзәк Комитеты күрсәтмәсе Татарстанда әле үтәлмәгән. Бу хәл күп кенә районнарда алдынгы колхоз яшьләрен ВЛКСМ сафларына кабул итүдә начар эшләүдән килеп чыга.

Партия оешмалары мәктәпләрдә эшне тәртипкә салуда комсомол алдына җидди таләпләр куярга һәм практик ярдәм күрсәтергә тиешләр. Мәктәпләрдә әле өлгерүчәнлек түбән, дисциплина начар, укучылар арасында шаянлык һәм хулиганлык фактлары күп.

Партиянең күп кенә райкомнарының, бигрәк тә башлангыч партоешмалар булмаган урыннарда (бездә 3.070 колхозда башлангыч партоешма юк) комсомолның зур ролен искә алмаганлыкларын күрсәтеп үтәргә кирәк. Райком секретарьлары ВЛКСМ ның башлангыч оешмаларының секретарьлары белән эшләмәделәр, аларның эшләренә тиешле юнәлеш бирмәделәр һәм шунлыктан кирәкле нәтиҗәләргә ирешмәделәр.

Партиябезнең тормышында иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе—бөек Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән кадрларны тәрбияләү һәм үстерү. ВКП(б) райкомнарында, шәһәр комитетларында һәм Өлкә Комитетында кадрлар бүлекләре төзелгәннән соң бу юнәлештә күп эш эшләнде. ВКП(б) Өлкә Комитеты республика һәм районнар күләмендәге барлык җитәкче кадрларны үз номенклатурасына алды. Төп игтибар ВКП(б) Өлкә Комитетының, шәһәр комитетларының һәм район комитетларының аппаратларына кадрлар сайлап алуга һәм туплауга юнәлдерелде. Сайлап алынган 1.540 кешедән Өлкә Комитеты бюросы 1.347 кешене, яки 87,5 процентын раслады.

Карт һәм яшь кадрларны бергә кушу турында иптәш Сталин күрсәтмәсе безнең оешмада да чагылды. Партия аппаратында эшләүче 239 работник яки 17,8 проценты ВКП(б) сафларына 1936 нчы елдан соң кергән. 1939 нчы елның икенче яртысы эчендә генә дә җитәкче партия, совет, хуҗалык һәм башка постларга 8.108 кеше күтәрелде.

Өлкә Комитеты бюросы үз номенклатурасының бары 55 процентын гына раслады. Бу—безнең кадрлар бүлеге эшнең күп кенә тармакларында кадрларны өйрәнүгә әле барып җитмәгән дигән сүз. Мәсәлән, ул мәгариф һәм культура кадрларын белми яки бөтенләй диярлек белми. Бюро раславына аларның бары 36,6 проценты гына кертелгән. Промышленность кадрларын ул тагын да начаррак белә. Ул аларның бары 6,6 процентын гына раслауга керткән.

1939 нчы елның икенче яртысында ВКП(б) райкомнары 992 кешене Өлкә Комитеты бюросы раславына керттеләр. Шулардан 131 кеше, яки 13,2 проценты кире кагылды. Бу, кадрларны сайлап алу һәм күтәрү эшенә тагын да җиддиерәк һәм уйлабрак карау өчен ВКП(б) райкомнары җитәкчеләрендә дә җаваплылык хисен күтәрмәгәнлегебезне күрсәтә.

ВКП(б) райкомнарының һәм шәһәр комитетларының саннарына караганда, аларда күтәрү өчен 1.658 кешелек резерв булдырылган. Шулардан 414 кеше партиясезләр. Ләкин мин шуны әйтергә тиешмен: бу саннар бик шикле. Практика бездә даими һәм тикшерелгән резервлар юклыкны күрсәтә, район һәм шәһәр комитетларында һәм хәтта Өлкә Комитетының үзендә дә еш кына җитәкчелеккә эштә тикшерелмәгән һәм өйрәнелмәгән очраклы кешеләр үткәреләләр.

Партия оешмаларының кадрларны сайлап алу һәм урнаштыру эшендә совет, хуҗалык һәм башка оешмаларның җитәкчеләрен кешеләрне тәрбияләүдә һәм үстерүдә системалы рәвештә эш алып барырга үзләрен мәҗбүр итәсе урында, алар урнына эшләүләре шундый ук җидди кимчелек булып тора.

⁂

Әгәр без ялгышларыбызны җидди төстә төзәтергә теләсәк, түбәндәге кимчелекләрне бетерергә тиешбез:

1. ВКП(б) га кабул итү эшенә җиңелчә якын килү практикасын бөтенләйгә бетерергә, бу эштә партия турында һәм анда член булып тору турында Ленин—Сталин таглиматын һәр вакыт кулланып эш итәргә. ВКП(б) сафларына яңа кабул ителгәннәр белән системалы һәм җидди эш алып бару кирәклекне бер кайчан да онытмаска. Коммунистларның язмышына җансыз һәм җиңелчә караш вакыйгаләренә, ВКП(б) сафларыннан нигезсез чыгару вакыйгаләренә юл куймаска.

2. Партия эчендәге демократияне нык саклап, большевистик тәнкыйтьне барлык чаралар белән оештырып, актив практик эшкә коммунистларның бөтен массасын даими рәвештә тартырга, партиябезнең эше өчен аларда җаваплылык хисен күтәрергә, партия җыелышларында „дәшми утыручыларның" һәм практик партия эшендә „эшсезләр"нең булмавына ирешергә.

3. Коммунистларыбызда теориягә тәм тудыру өчен ныклап көрәшергә, аларда үзләренең көчләренә, Маркс — Энгельс — Ленин — Сталин таглиматын үзлекләреннән өйрәнү сәләтенә ышаныч булдырырга һәм аны ныгытырга, марксизм - ленинизмны үзләштерүдә аларга күбрәк һәм яхшырак ярдәм итәргә. Теоретик уку формаларын сайлап алуның ирeклеге турындагы төшенчәне бозмаска һәм марксизм - ленинизм нигезләрен үзлегеңнән өйрәнү сылтавы астында бу өлкәдә асылда бер нәрсә дә эшләмәүчеләрне фаш итәргә. Коммунистларның һәм партиясез большевикларның теоретик хәзерлеген күтәрергә, халык арасында бөтен агитация эшен тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрергә. Агитацияне бушка гына үткәрмәскә, бәлки партия оешмасының агымдагы бурычларына нык бәйләп алып барырга.

4. Капиталистик чолганыш яшәгәндә совет халкы дошманнарының, коммунизм дошманнарының безгә үзләренең агентларын һәр вакыт җибәреп торачаклары турында иптәш Сталин күрсәтмәсен һәр вакыт истә тотарга. Моны истә тотарга һәм илебезнең оборона куәтен барлык чаралар белән ныгытырга, Осоавиахим оешмаларын һәм башка төрле оборона - физкультура оешмаларын киңәйтергә һәм ныгытырга. Бернинди очраклыклар да безне көтелмәгән хәл алдында калдырмасын өчен халкыбызны сүздә генә түгел, бәлки эштә дә мобилизация хәзерлеге хәлендә тотарга. Коммунистларның гына түгел, бәлки бөтен хезмәт ияләре массасының революцион уяулыгын һәр вакыт күтәрергә.

5. ВЛКСМ ВКП(б) ның беренче һәм ышанычлы ярдәмчесе икәнлеге турында партиябезнең XVIII нче съезды карарын аңларга һәм тормышка ашырырга. Комсомолецларны актив дәүләт һәм партия эшенә хәзерләү рухында тәрбияләргә.

6. Иптәш Сталинның „Кадрлар барсын да хәл итәләр" дигән лозунгысын сүздә генә түгел, бәлки эштә дә кулланып эш итәргә һәм кадрлар белән эшләүне фәнни югарылыкка кую кирәклеге турында иптәш Сталин күрсәтмәсен үтәүне практик төстә тәэмин итәргә.

⁂

Нинди йомгак ясарга мөмкин соң?

Партиянең Татарстан оешмасының отчет чоры эчендәге эшендә җидди һәм әһәмиятле уңышлар һәм казанышлар бар, ләкин әле кимчелекләр һәм хәтта ялгышлар да аз түгел. Алар отчетта күрсәтелделәр, ләкин һич тә тулысынча түгел әле. Партиянең өлкә конференциясенең бурычы—большевикларча җидди тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү нигезендә, эшебездәге барлык кимчелекләрне күрсәтү, чөнки үтелгән этапка бары тик аек төстә бәя бирү генә безгә кимчелекләрне бетерүдә, димәк, партия оешмасының бөтен эшен тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрүдә дөрес юл табарга ярдәм итәчәк.

Партиянең Татарстан оешмасы моңарчы булмаган дәрәҗәдә бердәм һәм тупланган. Ул сәламәт һәм сугышка сәләтле һәм бу—аның алга таба уңышлы баруының иң ышанычлы залогы.

Партиянең Татарстан оешмасы партиябезнең бөек Ленин—Сталин эше өчен, коммунизм өчен чын күңелдән бирелеп көрәшергә сәләтле, турылыклы һәм чын күңелдән бирелгән отрядларының берсе булып килде, шулай булып тора һәм шулай булыр. (Озакка сузылган кул чабулар).



Партиянең Алабуга районы делегатлары ВКП(б) ның Татарстан Өлкә конференциясендә. РӘСЕМДӘ: Ф. А. Костин (басып тора), утыручылар (сулдан): А. А. Петров, В. Р. Рәхимов, И. З. Гайфеттинов, А. С. Митюшкин иптәшләр. М. Солтанов фотосы.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә конференциясе көндәлеге

Конференциянең кичәге иртәнге утырышында ВКП(б) Өлкә Комитетының эше турында татарлардан да доклад һәм Ревизия Комиссиясенең рус телендә отчет докладлы тыңланды.

Беренче мәсьәлә буенча докладны ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Мухаметов** ясады, ВКП(б) Өлкә Комитеты Ревизия Комиссиясенең отчет докладын иптәш **Арнаутов** чыкты һәм конференциянең иртәнге утырышы шуның белән тәмам булды.

* *

Конференциянең кичке утырышы ВКП(б) Өлкә Комитеты Ревизия Комиссиясенең отчет докладын татар телендә тыңлаудан башланды. Бу докладны иптәш **Әхтәмов** ясады. Шуннан соң конференция ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Ревизия Комиссиясенең эше турындагы отчет докладлары буенча фикер алышуларга күчте.

Фикер алышуларда беренче булып, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателенең урынбасары иптәш **Афанасьева** чыгып сөйләде. Ул үзенең речендә ВКП(б) ның Татарстан оешмасы партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган бурычларны тормышка ашыру буенча шактый уңышларга ирешкәнлеген күрсәтү белән бергә, конференциянең игътибарын практик эштә булган кимчелекләргә һәм аларны бетерүгә юнәлдерә.

— Халык мәгарифе өлкәсендә зур гына уңышлар булу белән бер рәттән, әле безнең күп кенә мәктәпләребездә балаларны коммунистик рухта тәрбияләү эше һич тә канәгатьләнерлек хәлдә түгел, шуның аркасында кайбер мәктәпләрдә укучыларның өлгереше бик түбән, дисциплинасызлык, хулиганлык фактлары бар. Ләкин Мәгариф Халык Комиссариаты һәм урыннардагы партия, комсомол, совет, профсоюз оешмалары бу эшкә һәр җирдә дә яхшы җитәкчелек итәләр дип әйтеп булмый әле. Бу зур җитешсезлекне кичекмәстән бетерергә, мәктәпләр эше белән системалы рәвештә шөгыльләнергә кирәк,—ди иптәш **Афанасьева**. Аннары, иптәш Афанасьева укый-яза белмәүчелекне бетерү, аз белемлеләрне укыту эшендә булган җитди кимчелекләргә тукталып, бу эшкә мәгариф органнарының һәм Татарстан Совнаркомының җитәкчелеген көчәйтергә кирәклекне күрсәтә.

Киров районы делегаты иптәш **Дельвин** үзенең речен партия пропагандасы эшенең куелышына һәм бу өлкәдә булган зур җитешсезлекләргә, аларны бетерү юлларын күрсәтүгә багышлый. Төп җитешсезлекләр итеп ул түбәндәгеләрне күрсәтә: җитәкче кадрларыбызның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү эше белән нигезле шөгыльләнмиләр, партия оешмалары кирәгенчә тикшермиләр, партия пропагандасы буенча оештырылган күп кенә түгәрәкләр әле һаман да начар эшлиләр, кайбер урыннарда түгәрәкләргә укуга тартылган иптәшләрнең составы төрлечә, шуның аркасында үтелгән темаларны үзләштерү түбән. Иптәш **Дельвин** ВКП(б) ның шәһәр һәм Өлкә Комитетларының пропаганда-агитация бүлекләре тарафыннан урыннардагы партия оешмаларына булышлыкның җитәрлек булмавын күрсәтеп үтә.

— ВКП(б) ның Зеленодольски шәһәр комитеты секретаре иптәш **Суганов** үзенең чыгышында Зеленодольски шәһәрендәге завод, фабрикаларның эшенә тукталып, аларда 1939 елның дәүләт планнарын үтәлеше канәгатьләнерлек булмавын күрсәтә. ВКП(б) ның Зеленодольски оешмасы отчет чоры эчендә үзенең сафына 177 кешене член итеп, 330 кешене ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алган, ләкин партиягә алу эшен регулярлаштыру белән җитди рәвештә шөгыльләнмәү нәтиҗәсендә, төп профессия эшчеләре арасыннан партиягә кабул ителүчеләрнең саны түбән булганлыкны әйтә. Аннары иптәш Суганов Зеленодольски шәһәренең хуҗалык төзелешенә бәйле булган мәсьәләләрне тиз арада чишүне республика оешмалары алдына куя.

ВКП(б) ның Минзәлә райкомы секретаре иптәш **Хакимҗанов** авыл хуҗалыгына җитәкчелек итү буенча Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатының эш стилен кискен рәвештә тәнкыйть итә. Аннары иптәш Хакимҗанов соңгы сайлауларда җирле Советларның башкарма комитетларына күп кенә яңа кадрлар күтәрелгәнлекне күрсәтеп, бу кадрларга Татарстан Совнаркомы тарафыннан булышлыкның һич тә җитәрлек булмавын әйтеп үтә.

ВКП(б) Өлкә Комитетының кадрлар бүлеге мөдире урынбасары иптәш **Постнова** үзенең речен кадрларны тәрбияләү, аларны сайлап алуга, аларга практик эштә булышлык күрсәтүгә багышлый.

Партиянең Татарстан оешмасы бу өлкәдә зур гына уңышларга ирешкән булса да, әле дә җитди кимчелекләр да барлыгын әйтеп үтә.

Кичке утырышта фикер алышуларда ВКП(б) ның Кайбыч райкомы секретаре Акчурин, Тәтеш районы делегаты Хәбибуллин, Татарстан АССР ның җирле промышленность халык комиссары Измайлова иптәшләр катнаштылар.

Конференциянең бүгенге утырышы көндез сәгать 11 дән дәвам итә.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ЛОНДОН, 10 март. (ТАСС). Авиация министрлыгы Англия хәрби һава флотының һәлак булган очучыларының яңа исемлеген игълан итте. Исемлектә үтерелгән 53 очучы һәм хәбәрсез югалган 15 очучы исемнәре күрсәтелә. Хәбәрсез югалучылардан 4 се үтерелгәндер дип уйлыйлар.

ПАРИЖ, 10 март. (ТАСС). Рәсми белдерүләрдә болай диелә: кичә „бөтен фронт өстендә дошманның патрульләре берничә тапкыр уңышсыз һөҗүм иттеләр. Пленга төшүчеләр бар. Авиациянең активлыгы түбән булды". Хәбәрләр буенча, бүген иртә белән фронтта бер нәрсә дә булмады".

БЕРЛИН, 10 март. (ТАСС). Германия армиясе верховный командованиесе сводкасында түбәндәгеләр әйтелә: „Мозель белән Пфальц урманы арасында артиллериянең һәм разведка отрядларының җанлы хәрәкәтләре. Сугыш башланганнан бирле Германиянең хәрби диңгез флоты дошманның һәм нейтраль илләрнең Англиягә баручы 331.543 тонна авырлыгында 46 танкерын батырды. Шулардан 32 се 230.125 тонна авырлыгында Англия танкерлары. Шулай итеп, Англия танкер флотының 10 проценты юк ителгән.

Германия авиациясе Көнчыгыш Франция өстендә күзәтү очышлары үткәрде. Көн урталарында Германия—Франция чигендә Германиянең „Мессершмидт" тибындагы 7 самолеты белән Франциянең „Моран" һәм „Кертисс" тибындагы 10 истребителе арасында сугыш булды. Сугыш нәтиҗәсендә Франциянең бер самолеты бәреп төшерелде.

ГИТЛЕРНЫҢ РЕЧЕ

БЕРЛИН, 10 март. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, бүген рейхсканцлер Гитлер 1914—18 нче елгы сугышта, шулай ук хәзерге сугышта һәлак булганнарның истәлегенә багышланган кыскача речь сөйләде.

Германия дошманнарының теләге Германияне вакларга гыйбарәт икәнлеген күрсәтеп, Гитлер, моңа җавап итеп Германия „тарихта кайчан да булганга караганда ныграк берләшкән" дип белдерде. Гитлер Англия һәм Франция тарафыннан Германиягә көчләп тагылган сугышның Германия җиңүенә кадәр дәвам итәчәген хәзер торганлыгын тагын бер тапкыр күрсәтте. Гитлер болай дип белдерде: „Бу көндә, без барлыгыбыз да Франциянең һәм Англиянең капиталистик власть башында торучылары Германия империясенә көчләп тагылган сугышның Германия тарихында иң зур җиңү белән тәмамланачагына тантаналы ант итәргә тиешбез".

СССР ның Берлиндагы илчелегендә кабул итү

БЕРЛИН, 10 март. (ТАСС). Кичә, 9 нчы мартта СССР ның Берлиндагы илчелегендә 11 нче февральдә Совет—Германия хуҗалык килешүенә кул кую уңае белән Германиянең промышленность һәм финанс түгәрәкләре вәкилләре өчен кабул итү булды. Кабул итүдә СССР ның Германиядәге тулы хокуклы илчесе иптәш Шкварцев, СССР ның сәүдә вәкиле иптәш Тевосян, СССР ның Германиядәге илчелеге һәм сәүдә вәкиллеге хезмәткәрләре, Германия хуҗалык министрлыгының, тышкы эшләр министрлыгының вәкилләре, Германия промышленностеның күренекле вәкилләре, хуҗалык делегациясе башлыгы Риттер һәм Германия хуҗалык делегациясе членнары катнаштылар.

СССР ның Германиядәге илчесе иптәш Шкварцев кыска речендә, 11 нче февральдә кул куелган хуҗалык килешүенең СССР һәм Германия өчен экономик һәм политик яктан зур әһәмияте барлыгын билгеләде.

СССР белән Германия арасында узара файдалы булуга нигезләнгән һәм алар бергәләшеп эшләүләре тагын да киңәйтүне күздә тоткан килешүне Риттер әфәнде үзенең җавап речендә, Германия—Совет арасында хуҗалык килешүе тезүнең Германия һәм Совет халыкларының дусларча политик һәм экономик элемтәләрен булачагын күрсәтеп үтте.

Кабул итү дуслар шартларда үтте.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Наньнин—Цинъчжоу тимер юлы районында кытай гаскәрләре япон пехотасының 1.000 кешелек отрядына атака ясаганнар. 3 сәгатькә сузылган сугышта япон гаскәрләре зур югалтулар кичергәннәр һәм артка чигенгәннәр.

Гуандун провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә япон гаскәрләре Сватоудан чыгып, Чаочжоу районына һөҗүм итә башлаганнар. Кытай гаскәрләре тарафыннан алып ташланганнар.

„Мьйбао" газетасының хәбәр итүенә караганда, 8 нче мартта япон гаскәрләре авиация һәм танклар ярдәме белән, Макао атавындагы Шициңе алганнар.

7 нче мартта япон гаскәрләре Гонконгтан 35 километр төньяк-көнчыгыштагы десант төшергәннәр һәм хәзерге вакытта Гонконгтан 30 километр төньяктагы Шэньчунга таба хәрәкәт итәләр.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Чжецзян провинциясенең төньяк өлешендәге Ханчжоу районында, япон гаскәрләре бу территориядәге кытай гаскәрләренә һәм партизаннарга каршы экспедицияләр оештыралар. Японнар Ханчжоу—Цзясин һәм Ханчжоу—Хучжоу линияләре буйлап хәрәкәт итәләр.

Хубэй провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә 4 нче мартта япон гаскәрләре Иочжоудан 30 километр көнбатышта Хунань провинциясенә барып җиткәннәр. Ләкин кытай гаскәрләре тарафыннан артка чигерелгәннәр.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Шаньдун провинциясенең көнчыгыш өлешендә кытай партизаннары Вэйсянь районында япон гаскәрләренә каршы атака ясаганнар. Сугыш 4 сәгать дәвам итә. Вэйсянь районында кытай партизаннары тарафыннан Аньцю районында кытай партизаннары күпләрне шартлаткан һәм берничә урында шоссе юлын җимергәннәр.

БОЛГАРИЯ ТЕЛЕГРАФ АГЕНТЛЫГЫНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

СОФИЯ, 9 март. (ТАСС). Болгария телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Төркия властьлары Болгариянең 2 нче мартта һава начар булганлыктан аларның Төркия территориясендә чиктән якын гына урында җиргә төшәргә мәҗбүр булган самолетын азат итәргә боерык биргәннәр.

АНГЛИЯ ҺӘМ ҺИНДСТАН

КАБУЛ, 10 март. (ТАСС). Һиндстанда Англия даирәләре органы „Сивил энд Милитэри газет" газетасының хәбәр итүенә караганда, Һиндстанда легаль оешма булган. Һиндстан милли конгрессын тыю турында хәбәрләр көчәя, чөнки конгрессның башкарма комитеты бюросы Англиягә карата дошманлык резолюциясе кабул иткән иде. Конгресс үзенең 15 нче мартка билгеләнгән сессиясенә кадәр үк тыелыр дип саныйлар. Англиянең рәсми даирәләре конгрессның дошманлык позициясенә зур ризасызлык белдерәләр. Газетаның язуына караганда, әгәр конгресска 53 нче сессиясен чакырырга һәм хәзерләнгән резолюцияне үткәрергә рөхсәт бирелсә, ул чагында конгрессның хөкүмәт белән сөйләшүләре мөмкин булмаячак һәм конгресска карата „Һиндстанны саклау турында" гы закон кулланылачак. Газета, үзәк хөкүмәткә Һиндстанда „закон һәм тәртип" урнаштыру кыен булмаячак, дип янау төсендә белдерә.

Шул ук газета Һиндстанның милли конгрессы башкарма комитеты бюросының 15 нче мартта Рәжгардагы сессиядә тикшерелергә тиеш булган резолюциясе проектының тулы текстын басып чыгарган.

Резолюция проектында болай диелә: „Конгресс, Англия хөкүмәтенең Һиндстанны сугышучы ил дип белдерүе һәм бу сугышны алып бару өчен Һиндстан халкыннан сорамыйча һәм аның ризалыгыннан башка Һиндстан ресурсларын эксплоатацияләү турыдан-туры мыскыл итү булып тора һәм азатлык сөюче халык моңа түзеп тора алмый, дип белдерә. Англия сугышны Һиндстан халыкларын, Азиядәге һәм Африкадагы башка халыкларны эксплоатацияләүгә нигезләнә торган үзенең империясен саклау һәм ныгыту өчен империалистик теләкләр белән генә алып бара. Бу шартларда, эксплоатация системасын дәвам иттерү һәм ныгыту өчен алып барыла торган бу сугышны конгрессның турыдан-туры да, яки читләтә дә яклый алмавы ачык. Конгресс Англия интереслары өчен Һиндстан гаскәрләрен сугышырга мәҗбүр итү уңае белән, шулай ук сугыш теләкләренә файдалану өчен Һиндстаннан материаллар һәм азык чыгару уңае белән ризасызлык белдерә. Һиндстан рекрутлары да, җыелган средстволар да Һиндстан халкының теләп биргән бүләге дип карала алмыйлар. Конгрессның членнары да, конгресска теләктәшлек күрсәтүчеләр дә сугышка кешеләр белән, акча һәм материаллар белән ярдәм күрсәтергә теләмиләр. Конгресс Һиндстан халкының тулы азатлык алудан башка бер нәрсәгә дә риза түгеллеген белдерә. Һиндстанның азатлыгы Һиндстанның доминион сыйфатында яки нинди дә булса башка төстә Англия империализмы орбитасында яшәве белән бергә була алмый. Мондый хәл Һиндстан халкының куәтенә туры килми һәм ул Һиндстанны күп кенә яклардан Англиянең экономик һәм политик системасына бәйле итәр иде. Һиндстан халкы үз конституциясенең структурасын һәм башка илләргә карата үзенең мөнәсәбәтен үзе билгели ала".

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

10 нчы мартта фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Выборг заливында безнең частьләр **Варие-Саари** атавын алдылар. Бу заливның көнбатыш ярында безнең частьләр төньяк **Нисалахти** местечкосын алдылар. Безнең частьләр **Питкяранта** шәһәреннән көнбатышта Ладога күлендәге **Вуоратсу** атавын алдылар. Суоярви—**Сердоболь** тимер юлындагы **Лоймола** станциясе районында разведка партияләренең көчәйтелгән эзләнүләре.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Шул вакытта дошманның 8 самолеты бәреп төшерелде.

Хезмәт ияләре депутатлары Казан Шәһәр Советының Башкарма Комитеты хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы депутаты иптәш

Зиннәт Вәли улы ВӘЛИЕВнең

шушы ел 9 нчы мартта вакытсыз үлүе уңае белән тирән кайгы белдерә һәм аның семьясенең кайгысын уртаклаша.

1—1

14 нче март, кич 7 сәгаттә Казан Дәүләт университетының органик химия аудиториясендә, Менделеев исемендәге **Бөтенсоюз Химия җәмгыяте Казан бүлегенең**, академик А. Е. Фаворскийның тууына 80 ел, фәнни-педагогик эш алып баруына 55 ел тулуга багышланган,

УТЫРЫШЫ ҮТКӘРЕЛӘ

Көн тәртибе: 1. Академик А. С. Фаворскийның юбилее турында **А. Е. Арбузов** доклады. 2. Академик А. Е. Фаворскийның фәнни эшлеклелеге турында **В. В. Евлампиев** һәм **Б. А. Арбузов** докладлары. 469—1

КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ

производстводан аерылып һәм аерылмыйча укытып Шнче класс шоферлар хәзерләү курсларына (көндезге һәм кичке группаларга)

УКУЧЫЛАР АЛА

Уку срогы: производстводан аерылып уку группасында 2 ай ярым, ә производстводан аерылмыйча уку группасында 5 ай.

Курсларда укыту расходлары өчен түләү 620 сум.

Укулар 15 нче марттан башлана.

Курсларга 18 дән түбән булмаган яштәге, кимендә 5 класс күләмендә белемле ирләр һәм хатын-кызлар предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, колхозлардан, совхозлардан һәм башка оешмалардан бирелгән командировка белән алыналар.

Гомуми ял көннәреннән башка һәр көн иртән 9 сәгаттән кич 7 гә кадәр, түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә: Казан, Кызыл Армия бистәсе, Кече Москва урамы, 16, 32 нче мәктәп. 463—1

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

12 нче мартта көндез 12 сәгаттә һәм кич

БИШБҮЛӘК

Талоннар: көндез 132, кич 133.

13 нче мартта

ШӘМСЕКАМӘР

Талон 134.

Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Зур драма театры бинасында.

Иртәгә, 13 нче мартта

ФАУСТ

Талон 87. Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 12 нче мартта көндез 12 сәгаттә

МАСКАРАД

Кич

КУРКЫНЫЧЛЫ БОРЫЛЫШ

Талоннар: көндез 24, кич 122.

Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Киров районындагы

КУЛЬТУРА САРАЕНДА

Бүген, 12 нче мартта

Халыкара Хатын-Кызлар көненә багышланган

ЗУР КОНЦЕРТ, КИЧӘ-БАЛ

ДЖАЗ, танцылар.

Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.

Талон 67. 2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген, 12 нче мартта, данлыклы

ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ

300 хәйван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган артисты орденлы **М. ЗОЛЛОның** соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Бүген, көндез 12 сәгаттә зур программа буенча **КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ.**

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, чит ил фильмы **КАТЕРИНА**
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	**КЕЧКЕНӘ АНА**
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	**ЯШӘРГӘ**
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	**УТ ТРАНСПОРТЫ**
„ПИОНЕР" 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	**ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП** Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	**МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ**
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	**УКЫТУЧЫ**
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	**ПАТРИОТ**

КИРӘК:

ТатТАСС редакциясендә эшләү өчен, ТАТАР һәм РУС ТЕЛЛӘРЕН БЕЛҮЧЕ СТЕНОГРАФИСТКА. Бауман урамы, Матбугат йорты, 3 нче кат, 52 нче бүлмә. 446—3—1

Казан тимер юлы команда составының техник курсларында өстәмә рәвештә эшләү өчен ХИМИЯДӘН, ЭКОНОМИК ГЕОГРАФИЯДӘН, МЕТАЛЛ һәм АГАЧ ТЕХНОЛОГИЯСЕННӘН УКЫТУЧЫЛАР. Казан, Ухтомский урамы, 12. Телефон: вокзал коммутаторы 0—43, ике звонок. 460—1

„ИРЕК"

(ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫНЫҢ ЯҢА ПОСТАНОВКАСЫ)

„Ирек" операсы белән композитор Нәҗип Җиһанов үзенең талантының никадәр зур, никадәр бай икәнен тагын бер кат раслый. „Качкын" операсындагы кебек үк, „Ирек" операсында да—гасырлар буена изелгән татар хезмәт ияләренең азатлык өчен көрәшүләре күрсәтелә. Әсәрдә төп герой итеп халык алына. Бу нәрсә композитор алдына зур җаваплылык куя һәм Җиһанов моны уңышлы башкарып чыккан. Җиде картинадан торган бу операның биш картинасы халыкның азатлык өчен көрәшен күрсәтүдән гыйбарәт. Моның өчен композитор төрле алымнар куллана. Әсәрнең җидедән биш өлеще дуэт, трио, квинтет һәм ике, дүрт, хәтта, урны белән 6—8 тавышка бүленгән хорлардан тора. Җиһанов монда зур мастерлыкка ирешкән. Мортаза белән Шаһвәли дуэты (1-пәрдә), Бибисара, Шаһвәли һәм Гарифлар тарафыннан җырлана торган трио (II-пәрдә) һәм III нче пәрдәдәге квинтет зур осталык белән язылганнар. „Качкын" операсында мондый ансамбльләр сагырак кертелгән булсалар, „Ирек"тә инде Җиһанов аларны кыю куллана. Бу ансамбльләр зур симфоник яңгырау астында гаят ямле, матур булып ишетеләләр.

Хорлар әсәрдә югары урын тоталар. Изелгән, кимсетелгән хезмәт халкының йөрәк әрнүен тирән моң белән бирә алган кебек („Уракчылар хоры", „Кара урман" һ. б.) Җиһанов үзенең хорлары белән халыкның протестын да, батырлыгын да, аның җиңү пафосын да зур осталык белән чагылдыра (баш күтәргән крестьяннәр хоры, финал хоры һ. б.).

Музыканың динамик үсеше дә, әсәрдәге драматик моментларның эмоциональ тулылык белән бирелүе дә, лирик күренешләр дә тирән һәм җидди язылганнар. Сәлимнең беренче һәм икенче арияләре, Бибисараның беренче ариясы, аның җылавы, бишек җыры, карт солдатка ариясы—болар барсы да тамашачыда тирән тойгы калдыралар. Бу арияларның темалары халык җырларына якыннар һәм солистларның (халык артисткасы Кайбицкая, артист Насретдинов, Байрашева, Сәйфетдинов, Булатова) оста язылган оркестр аккомпонименты астында аларны үтәүләре искиткеч матур яңгырыйлар.

Җиһанов музыкаль темаларны уңышлы таба һәм алар белән идарә итә белә. Ул үзенең темаларына гаят тирән эчтәлек сала. Мәсәлән, Сәлим темасы. Бу тема—Сәлимнең арияларында булсын, речитативларында булсын—иң югары үсешкә җитә һәм шул ук тема 4 нче пәрдә алдыннан уйнала торган антракта Сәлимнең үлүе турында да сөйли. 3 нче пәрдәдәге 1 нче картинаның музыкасы аеруча кайнар тойгы белән язылган.

„Ирек" операсын сәхнәдә тиешенчә яңгырату өчен Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе дирижер С. С. Бергольц күп көч куйган. Моны ансамбльләрнең агышыннан, хорларның тигез һәм яхшы бирелүләреннән, оркестрның гаят ягымлы, тигез уйнавыннан да аңлап була. Бергольц операның төп идеясен яхшы аңлаган һәм аны халыкка җиткерүдә зур осталык күрсәткән. Көчле, күтәренке моментлар булсын, яки лирик күренешләр булсын—берсе дә музыканың динамик үсешен истән чыгармыйлар һәм дирижер операда катнашучы барлык көчләрне ныклы дисциплина белән финалга, җиңүгә алып бара.

Операның кайбер җитешсезлекләренә тукталганда Җиһановның музыкаль телендә „Качкын"га караганда алга китү булса да әйтергә кирәк. Шамиль образы Сәлимгә, Бибисарага караганда бераз салкынрак бирелгән. Шамильнең музыкаль образы колакта калмый. Дөрес, ул ышандырырлык ритмда бирелгән, ләкин тагын нәрсәдер җитми кебек әле. Бу хәл бигрәк тә М. Алеев башкаруында сизелә. Ягымлы, йомшак тавышлы Алеев сәхнәдә Шамильнең җиддилеген, көрәштә җитәкче ролен биреп бетерми. Артемовның Шамиленә күбрәк ышанасы килә. Ул биргән большевик образы кыюырак һәм батыррак булып чыга.

Күренекле образлардан тагын Хаят белән Гарифны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Зарова башкаруында Хаят операның төп героинясе булу дәрәҗәсенә үсә. Комик планда эшләнгән Гариф образы үзенең яхшы башкаручысын көтә. Хәзергә моны Ростовцев та, Маннапов та (бу соңгысы беренчесенә караганда яхшырак булса да) биреп җиткермиләр әле. Аларның уенында юмор аз, җылылык аз.

Хәйләкәр, ерткыч Мортаза һәм кискен характерлы явыз Шаһвәли образлары композитор тарафыннан тулы сурәтләнгәннәр. Мортаза партиясын Бичурин да, Верниковский да уңышлы башкаралар, ә кайбер урыннарда Бичуриннең Мортазасы табигыйрәк һәм уңышлырак та чыга. Шаһвәли ролендәге Маев җыр партиясен тигез, яхшы үтәве белән генә түгел, үзенең оста уены белән дә типның усал табигатен ачып бирә. [illegible] бирелеп китеп, музыкаль характеристикага зарар китерә.

З. Сафин иптәшнең либреттосында, драматургия законнарына буйсынган әдәби әсәр булу ягыннан, зур кимчелекләр бар. Иң башлап либреттода таркаулык нык сизелә. „Кызганыгыз минем хәлемне", „Кыен кирәк" шикелле ятышсыз җөмләләр дә, кытыршы сүзләр дә очрыйлар.

„Ирек" операсы спектакленең иң җитешсез ягы—либреттоның йомшак булуы белән бер рәттән, аның режиссер Сарымсаков тарафыннан эшләнми калуы. Әсәрдә, әйткәнебезчә, төп герой булып халык бара. Теге яки бу вакыйгага карата халыкның мөнәсәбәтен, карашын, настроениесен күрсәтү өчен Җиһанов иптәш гаять матур музыка бирә. Бергольцнең дирижерлык таягы астыннан залга көчле, ягымлы музыкаль тавышлар ява. Халыкның батырлыгын, кыюлыгын, иреккә омтылуын күрсәтү өчен композитор биргән тавышларда күк күкрәве ишетелгәндәй була. Халыкның вакытлыча җиңелгән моментларында (мәсәлән, Сәлим үтерелгәч) оркестр, җылагандай, залга кайгылы авазлар сибә. Режиссер Сарымсаков шуны күзгә күренерлек итеп сәхнәдә күрсәтергә тиеш иде. Сәхнәдәге масса күренешләре шул көчне бирү түгел, күп урында алар музыка тактына да туры килмиләр.

Художник Шипулин музыка өчен күзгә ягымлы, йомшак буяулар тапкан. Өченче пәрдә картиналары (Бибисара өе, кыр) һәм урман пәрдәсе (ике айның берсен алып ташлаганда) аеруча яхшы эшләнгәннәр. Шипулинның бу картиналардагы уңышлы хезмәтен тамашачы алкышлап каршылый. Ләкин икенче пәрдәдә һәм дүртенче пәрдәнең икенче картинасына ясалган оформление спектакльгә уңышлык кертми. Чөнки алар „Качкын" оформлениесен хәтерләтәләр. „Качкын" да Бикә өе сулда булса, „Ирек"тә Мортаза өе унда. Арткы пландагы тар күпер дә „Качкын"нан күчерелгән кебек. Аерма бик аз. Димәк, кабатлау бар, ә кабатлау—иҗад түгел. Кызганычка каршы, Шәмсеттинев куйган биюләр дә безне канәгатьләндермәде.

Күрсәтелгән җитешсезлекләргә дә карамастан, „Ирек" операсы спектакле үзенең музыка көче белән совет сәнгате дөньясында зур яңалык, татар совет культурасы өчен зур уңыш.

Югары бәягә ия булган бу кыйммәтле әсәрне тиешенчә сәхнәгә куяр өчен опера театры аның постановкасын (либреттосын һәм режиссер эшен) яңадан үзгәртергә тиеш.

Операны кабат-кабат тыңларга кирәк. Аның сүзләре, эчтәлеге тамашачыга алдан ук билгеле булырга тиеш. Театр дирекциясе куела торган операларның либреттоларын бастырып таратырга (кыскартып түгел) һәм операны ничек тыңлау турында тамашачылар белән беседалар уздырырга тиеш.

Җәүдәт Фәйзи.
Гадел Кутуй.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.